## ТӘРТИП БУЛСЫН!

Президент Рөстәм Миңнеханов киткән егетләргә шартлар булдырырга, гаиләләренә ярдәм күрсәтергә кушты

> 2

## КЫЛ ЯХШЫЛЫК

Карина Шиһапова кечкенә шәһәрдәге зур эшләр турында сөйли

> 5

## СӨЙЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ!

Берлинга кадәр барып җиткән Самра Бикмеева турындагы серләрне аңа 100 яшь тулгач кына белдек

> 5

## БОЛГАНЧЫК ЕЛЛАР

Дөньяда ни генә булмасын, кеше бәхеткә омтыла...

> 6


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 164 (28937) | Сишәмбе | 8 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat


# МӘКТӘПЛӘРДӘ КИЧЕН... УТЛАР ЯНА

## КЕМ ӨЧЕН?

**Укырга бервакытта да соң түгел. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, быелгы уку елында кичке мәктәпләрдә 1300 кеше белем ала. Әлеге уку йортлары Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләре, Кукмара, Менделеевск, Яшел Үзән, Питрәч районнарында ачылган. «ВТ» хәбәрчесе кичке мәктәпләрдәге вазгыять турында белеште.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Быелгы уку елында республикада 10 кичке мәктәп эшли. Шуларның тугызы район һәм шәһәрләрдә урнашса, берсе республика буенча Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенә (УФСИН) карый. Кичке мәктәпләрдә укучыларның саны елдан-ел кими. Мәсәлән, соңгы ике елда андыйлар 300гә азрак. Иң яше 8 нче сыйныфта укый. Шул ук вакытта 30 яшьтән узган өлкәннәр дә бар. Күбесе укуын техникумнарда дәвам иттерү, эшкә урнашу өчен аттестат алырга дип килә. Теләгәннәр БДИ тапшыра ала, – дип белдерделәр министрлыкның матбугат үзәгендә.

Бу көннәрдә матбугатта Чаллының мәгариф идарәсе башлыгы Рөстәм Хуҗинның автокаладагы кичке мәктәпләр турындагы мәгълүматы күзгә чалынган иде. Шәһәрдә 1 нче сыйныфларда 51 бала укый, аларга – 6, ә шәһәрнең иң өлкән укучысына 46 яшь икән. Ул 65 нче мәктәптә 11 нче сыйныфта белем ала. Аны эзләп, Чаллыдагы кичке мәктәпкә шалтыраттык. Биредә 200дән артык кеше укый.

– Әлеге хатын-кыз укый башлады, аннан авырып китте. Белешмә алып килде, әмма үзе әлегә күренми. Килерме, белмибез... Укырга теләге әллә ни юк, ахры. Телефон номерын бирә алмыйбыз, – диде директор Ольга Волкова.

Директор әйтүенчә, кичке мәктәптә 15тән 48 яшькә кадәрге кешеләр укый. Күбесе 17–19 яшьлекләр. «Кемдер техникумны бетерә алмаган, укымыйча армиягә киткән, кемдер яшьли бала тапкан. Заводта эшләүчеләр дә бар. Барысы да, алга таба үсәр өчен, аттестат кирәклеген аңлаган, – ди директор. – Бездә көндез һәм читтән торып уку формасы бар. Фәннәрнең бер өлешен кичен укыйлар. Конституциядә, һәркем бушлай урта белем алу хокукына ия, диелгән. Әгәр кеше гыйлемне үз вакытында алмаган икән, хәзер алырга мөмкин. Бу форма кирәк. Һәр кечкенә бистәдә кичке мәктәпләр тотуның мәгънәсе юктыр, әмма зур шәһәрләрдә ансыз булмый.

Кукмара мәгариф идарәсе башлыгы Илфат Әхмәдуллиннан да кичке мәктәп турында сораштык. Киләсе уку елында ул ябылырга да мөмкин икән. Ни өчен дигәндә, укучылар саны аз. Бу очракта аны һәр мәктәп үз базасында оештырачак.

– Бездә кичке мәктәптә 19 бала укый. Барысы 12 класс эшли. 7 нче сыйныф укучыларыннан башлап, техникум студентларына кадәр бар. Иң олысына – 20 яшь. Өлкәннәр юк. Күбесе – техникумга китеп, кире кайтучылар. Кайбер әти-әниләр гаилә бюджетын арттыру өчен, балаларын кичке мәктәпкә урнаштыра, көндез алар эшли. Ул ягы да бар, –диде Илфат Әхмәдуллин. – Соңгы вакытта мәктәпләрдә авыррак укучыларны да шунда җибәрә башладылар. Укымаган бала белән дә мәктәп үзе шөгыльләнергә тиеш. Кичен алган белем – кичен алган инде ул. Хәзер башка заман. Элеккеге кебек наданлыкны бетерү өстендә эшләмибез. Хәзер мәгариф бик нык үсештә. Уку өчен шартлар тудырылган, яхшы укытучылар укыта.

Азнакай районында яшәүче пенсиядәге укытучы Алсу Габделхакова фикеренчә, кичке мәктәп химия, биологиядән генә торырга тиеш түгел.

– Бездә юридик наданлык көчле. Анысын да шунда аңлатырга кирәк. Шулай ук үзмәшгульлекне оештырырга, эшмәкәрлеккә өйрәтеп булыр иде. Кичке мәктәпләр укымыйча калган бер катлауны җәлеп итәргә тиеш. Яңа типтагы заманча кичке мәктәпләр кирәк. Уку бервакытта да модадан да чыкмый, барлык диннәр дә аны хуплый. Китапханәләрдә ачарга кирәк кичке мәктәпләрне. Аларга берәр үзенчәлеклерәк бердәм исем дә кушарга була. Һич югы, эшчеләр факультеты, тормыш мәктәбе дип үзгәртергә мөмкин, – диде Алсу Габделхакова.

Ахыры 2 нче биттә >

## Төзелешкә акча кызганмыйлар

Быел гыйнвар – сентябрь айларында Татарстанда төзелеш эшләренә барлыгы 328,7 миллиард сум акча тотылган. Бу – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 13,5 процентка күбрәк. Сентябрь аенда гына төзелештә 59 миллиард сумлык эш башкарылган. Узган елның шушы ук аендагыга караганда – 22,5 процентка һәм быелгы август ае күрсәткеченә караганда 1,1 процентка күбрәк сан бу.

Кече эшмәкәрлеккә кермәгән оешмалар гыйнвар – сентябрь чорында җәмгысы 117,8 миллиард сумлык төзелеш эшләре башкарган. Әлеге сан узган елның өч кварталындагыга караганда өчтән бер өлешкә диярлек күбрәк.

Исегезгә төшерәбез: быел өч кварталда Татарстанда 2,7 миллион квадрат метрдан артыграк торак мәйданы төзелгән. Бу – узган елның шушы ук чорындагыдан 21,6 процентка күбрәк.

## *Алар әзер*

Татарстанда яшәүче ярты миллионнан артык кеше (553804) ГТО нормативын үтәгән. Шуның 82132се – алтын, 102696сы – көмеш, 106013е бронза билгегә лаек булган.

Бүген республикада ГТО үтәү өчен 55 үзәк эшләп килә. Быел тагын 6 мәйданчык: Әлмәт, Кайбыч, Лениногорск, Балык Бистәсе, Тәтеш, Югары Ослан районнарында мәйданчыклар ачу күздә тотыла. Әлеге эш «Демография» илкүләм проекты кысасында алып барыла.

ГТОны үстерү өлкәсендә иң көчле 10 район исемлегенә Буа, Чүпрәле, Саба, Балтач, Апас кебек районнар кергән.

Сүз уңаеннан, Татарстанда «Демография» илкүләм проектын 4 ел (2019–2022 елларда) тормышка ашыру барышында 31 спорт корылмасы төзекләндерелгән, авыл мәктәпләрендә 147 спорт залы ремонтланган, районнарда ГТО тапшыру өчен 31 мәйданчык булдырылган.

## Бәхет өчен... күп кирәк

Казанда яшәүчегә, үзен бәхетле хис итү өчен, аена уртача 175 мең сум акча кирәк. SuperJob эш эзләү онлайн хезмәте шундый мәгълүмат китергән. Тикшеренү нәтиҗәләренә караганда, быел апрель аенда да бу күрсәткеч 175 мең тәшкил иткән. Узган елның ноябрендә – 174 мең сумга, маенда – 163 мең сумга, ә гыйнварында 158 мең сумга тигез булган. 2019 елда бәхет арзанрак торган – 160 мең сум, 2018 елда 158 мең сум белән исәпләнгән.

Күңеле иң күп акча теләгән шәһәрләр бишлегенә Мәскәү (250 мең сум), Ростов-Дон (205 мең), Владивосток, Екатеринбург, Красноярск һәм Төмән (200әр мең сум) кергән. Шул ук вакытта ярты ел эчендә Новокузнецкида бәхет «хак»ы – 6 процентка, Кемерово һәм Ижевскида 3 процентка кимегән. Ә менә Новосибирскида, киресенчә – 10 процентка, Мәскәүдә – 9, Краснодарда 8 процентка арткан.

Сүз уңаеннан, октябрь аенда Казанда иң күп хезмәт хакы вәгъдә ителгән вакансияләр рейтингында тукыма кибетендә сатучы беренче урынга чыккан. Эш бирүчеләр аңа 150 мең сумга кадәр хезмәт хакы түләргә әзер. Икенче урында – логистика буенча менеджер вакансиясе.

Яңалык

# Тыю хәерлерәк

**Татарстанда 18 яше тулмаганнарга энергетиклар һәм кабызгычлар (зажигалка) сату һәм сатып алу тыелачак. Тиешле закон үз көченә 12 ноябрьдән керә. Закон үтәлмәгән очракта, алучыга да, сатучыга да саллы гына штраф каралган.**

Әлеге закон проектын республика прокуроры Илдус Нәфыйков Татарстан Дәүләт Советының сентябрь ахырында узган утырышында тәкъдим итте. Сүз 18 яше тулмаганнарга тонусны күтәрә торган хәмерсез эчемлекләр (энергетиклар) һәм сыекландырылган углеводород газы кергән товарлар (кабызгычлар) сату турында бара. Илдус Нәфыйков аңлатканча, яшьләр арасында әлеге товарларның популярлыгы көннән-көн арта гына. «Алар көн саен, ким дигәндә, 250 мл күләмендә энергетик эчә. Ә составында кофеин, таурин кебек зарарлы компонентлар булган эчемлекләрне мондый күләмдә эчү сәламәтлек өчен бик зыянлы. Бу наркомания, алкоголизм, симерү кебек авыруларга китерергә мөмкин. Өстәвенә энергетиклар балалар өчен зыянлы продуктлар исемлегенә дә кертелгән», – диде Татарстан прокуроры.

Илдус Нәфыйков кабызгычлар сатуны тыюның сәбәбен дә атады. Ул да булса – бүген үсмерләр арасында популяр булган «сниффинг» күренеше. Бу күренеш кабызгыч яки аның баллоныннан углеводород иснәүдән гыйбарәт. Моңысы исә йөрәк ритмы бозылу яки йөрәк тибешенең бөтенләй туктавы белән тәмамланырга мөмкин. Татарстанда шушы рәвешле уеннан уймак чыгаруның быел бер очрагы теркәлгән инде. Чаллыда яшәүче кыз бала бутан иснәп

ru.pinterest.com

җан биргән. 2021 елда да Чаллыда газ белән агулануның өч очрагы теркәлгән булган.

Нәтиҗәдә әлеге закон проектын Татарстан депутатлары да, Президент та хуплады. Рөстәм Миңнеханов тиешле карарны 2 ноябрьдә имзалады. Закон үз көченә 12 ноябрьдә керәчәк.

Хәзер алда саналган товарларны сатып алучыларга – 3 меңнән алып 5 мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – 30 меңнән алып 50 мең сумга кадәр, ә оешмаларга 100 меңнән алып 150 мең сумга кадәр штраф түләргә туры киләчәк.

Әлеге законны Россия Дәүләт Думасы депутатлары да хуплаган. «Парламентская газета» хәбәр итүенчә, Татарстаннан Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов законның актуальлеген, әмма аны федераль дәрәҗәдә кабул итүнең дәвамлы эш булуын искәрткән.

Сүз уңаеннан, балигъ булмаганнарга энергетиклар сату, Татарстаннан тыш, тагын 40лап төбәктә тыелган. Кайбер төбәкләрдә үсмерләр кабызгычлар да сатып ала алмый.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

**Сан**

Дәүләт Думасының Куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәш комитеты әгъзасы Бийсултан Хамзаев сүзләренә караганда, 2018–2021 елларда илдә ел саен «сниффинг»тан 350ләп үсмер үлә.

**Сүзгә-сүз**

**Наил МӘҺДИЕВ, Чаллы мэры:**

Балалар өчен бәйрәмнәр гадәттәгечә узачак. Яңа ел – беренче чиратта балалар өчен, без аларны бәйрәмсез калдыра алмыйбыз. Илдә хәлләр ничек кенә авыр булмасын, безнең бурыч – бакчаларда һәм мәктәпләрдә балаларны игътибарсыз калдырмау. Бүләкләр, Кыш бабай, Кар кызы – барысы да булырга тиеш. Безнең мөмкинлекләр җитәрлек.

**(Шәһәр мэриясендәге утырышта сөйләгәннәрдән)**

## ТАТАРСТАНДА – ТРАНСПОРТ

**Россия Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021 ел ахырында Татарстанда 1202176 җиңел машина теркәлгән. Бу – алдагы ел белән чагыштырганда 19299 автомобильгә күбрәк.**




## *Җылы кара көз*

Бу атнада Татарстанда шактый ук җылыта. Синоптиклар хәбәр иткәнчә, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе – 9–10 ноябрьдә яңгырлы юеш кар көтелә. 9 ноябрьдә термометрның терекөмеш баганасы көндез 0…+5, төнлә –3…+2 градуска кадәр күтәреләчәк. 10 ноябрьдә көндез +2…+7 градус, төнлә 0…+4 градус. Бу көннәрдә уртача температура нормадан 3–4 градуска югарырак булыр дип фаразлана.

Башлангыч фаразларга караганда, атна ахырында – 11–12 октябрьдә республикада яңгырлар явып үтәчәк. Җылы: көндез +2…+7, төнлә 0…+5 градус.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Дөньяда**

## БАЙДЕН ИРАННЫ «АЗАТ ИТӘ»

Дөньякүләм киеренкелекне көчәйтү өчен, лидерлар барысын да эшли. Үткән атнада халыкларны зур сугыш кочагына ташлау юнәлешендә зур адымнар атладылар. Ноябрь башында Урта диңгезгә атом коралы йөртә торган иң зур су асты көймәсе килеп керде. Америкалыларның USS Rhode Island дип аталган көймәсе континентара 24 баллистик Trident II атом-төш ракетасы йөртә. Tridentлар бер сәгатькә 29 мең километр тизлектә 18 мең километрга кадәр очалар. Көймә бортында 200дән артык атом-төш очлыгы бар, дип әйтәләр. Аның «Кыямәт җайдагы» дигән исеме дә бар. Американнар, әлбәттә, мускуллар гына уйнаталар. Бу – нигездә, Россиягә янау, Мәскәүнең атом коралы куллану белән куркытуына җавап.

Якын Көнчыгышта киеренкелек үсә башлады. 2022 елның 9 гыйнварында газета сайтына эленгән үземнең язмамнан бер өзекне исегезгә төшерер идем. Ул чакта Трамп Иранга каршы сугыш башлау белән янады. Без исә болайрак яздык: «Трампның америкалыларга мөрәҗәгате шарның «пышш» итеп шиңүе кебек эффект бирде. Һәркем җиңел сулады: сугыш булмаячак. Менә шундый көтелмәгән борылышның булачагын «Ватаным» хәбәрчесе алдан белеп торды һәм декабрь уртасында ук бу хакта хәбәр итте. Әмма Иран тирәсендә киеренкелек туктамаячак, аерым ракета һөҗүмнәре дә булырга мөмкин. Бар максат Иранда зур болганчыклык тудыруга юнәлтеләчәк. Моңа берничә ел вакыт сарыф ителер дип уйлыйбыз». Әйе, әйе, 2022 елга фаразлар язганда ук, без Иранга каршы сугыш булмаячагын әйткән идек, әмма зур фетнә әзерләнәсен фаразладык. Безнең фараз йөз процентка тормышка ашып ята. Сентябрьдән бирле Иранда гыйсъянчылар котырына. Корал куллану да, кан түгелү дә фетнәне туктата алмый. Үткән атнада фарсылар Җәмкаран мәчете манарасында кызыл байрак күтәрделәр. Моны үч алу һәм сугыш игълан итү билгесе дип аңлаттылар. Соңгы тапкыр кызыл байрак манарага американнар Сөләйманине үтергәч эленгән иде. Фарсылар Гыйрактагы Америка базасына баллистик ракеталардан «яңгыр» койдырдылар ул чакта. Трамп сугыш игълан итәргә маташты, без аның ул тырышлыгының тормышка ашмаячагын әйттек.

Калифорниядә сайлаучылар белән очрашканда, мобиль телефоннарына «Иранга азатлык!» дип язып, өскә күтәргән протест белдерүчеләргә Байден да: «Дулкынланмагыз, без Иранны азат итәбез», – диде. Америка разведкасы шулай ук: «Иран Согуд Гарәбстанына каршы сугыш башлый», – дигән хәбәр дә таратты. Рәсми Тәһран моны кире какты. Автор исә: «Бөек вакыйгаларның увертюрасы уйнала, Якын Көнчыгышта тектоник үзгәрешләр әзерләнә», – дип, җаваплы рәвештә игълан итә. Россия – Украина конфликтының чишелеше дә шул үзгәрешләргә турыдан-туры бәйле дип уйлыйбыз. Вәләкин вакыйгалар горизонтын әйтә алмыйбыз. Шуңа күрә газета хәбәрчесенә бу хакта сорау биреп шалтыратмагыз. Бер генә нәрсәне әйтә алам: бу хакта язганда, күздән яшь ага.

**Россиядә**

## ДӘҮЛӘТ – ИНВЕСТОР ДА, ТАБЫШ АЛУЧЫ ДА

Россия икътисады кыенлыклар зонасыннан чыгарга азапланып талпына. Халык куллануы товарлары җитештерүче сәнәгать (әйтик, автомобильләр җитештерү) зур түнү белән түнде. Әмма базар муллыгы дәвам итә әле. Халык сатып ала алмый торган товарлар исемлеге үсә, муллыкны шул тәэмин итә. Аның каравы хәрби максатлар өчен кирәк-ярак җитештерү арта: танклар, хәрби очкычлар, ракета-снарядлар санын арттыру юнәлешендә зур тырышлык куела. Эчке тулай продуктны шул тотып тора да инде, чөнки корыч, төсле металлар һәм башка чимал күп таләп ителә. Вәләкин коралга ихтыяҗ бик зур әле. Мобилизацияләнгәннәр кулына иске автоматлар тоттыру очраклары бер генә тапкыр булмады. Җитмәсә кулына корал тотучыларга вәгъдә ителгән зур суммалар да керми. Бу зур дулкынлануларга сәбәп була. Хәрби комиссариатлар 195 мең сумлык түләүнең 10 ноябрьдән дә иртә кермәячәген әйтеп тынычландыралар. 2 ноябрьдә Путин да Кораллы көчләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерү буенча Координацион советның икенче киңәшмәсен үткәрде. Лидер сугыш кирәк-яраклары җитештергәндә бюрократиянең аяк чалуыннан зарланды. «Шартлар безнең бөтенләй башка режимда эшләвебезне таләп итә. Эш шулай оештырылырга тиеш: безгә кирәкле конкрет нәтиҗәгә ирешергә берни дә комачауламасын», – диде ул һәм җитештерүчеләрнең, проектлаучыларның конкуренциясен оештырырга чакырды. Әйе, сер түгел: бүген хәрбиләр кулына тоттырылган корал һәм экипировка бернигә дә ярамаган очраклар бар. Шуңа күрә яңаны эшләгәндә, хәрбиләр белән киңәшергә кирәк. Путинның тел төбендә шул ята. Соңгы унъеллыкта оборона максатларында гаҗәп күп акча тотылды, әмма нәтиҗәсе куанычлы түгел.

Корал җитештерү артуга карамастан, Россиянең эчке тулай продукты кимү дәвам итә. Сентябрьдә ул 5 процентка җиткән, ди Икътисади үсеш министрлыгы. Инвестицияләр кими, бизнес яңа проектларга акча тотмый диярлек. Бу алдагы елларда зур кайтаваз бирәчәк. Икътисади үсеш министрлыгы, инвестицион активлыкны арттыру өчен, бар көчен биреп тырыша. Ләкин яңа проектларны финанслау дәүләт җилкәсенә генә төшәр, мөгаен. Министрлыкта дәүләтне «соңгы инстанциядәге инвестор» дип атый башладылар инде. Хөкүмәт инвесторларның иртәгәге көнгә ышанычын кире кайтарырга тырышмый түгел, тырыша. Төрле өстенлекләр кертергә омтыла, әмма өстенлекләр исемлеге хосусый инвесторларны шатландырмый. 3 ноябрьдә Президент янындагы киңәшмәдә Решетников дәүләтнең турыдан-туры җитештерү өчен акча кертү юлы белән дә, инвесторларның югалтуларын каплау һәм проектларны инфраструктура белән тәэмин итү өчен финанслар бүлену юлы белән дә активлыкны арттырырга тырышуын әйтте. Беренче яртыеллыкта дәүләтнең капитал кертемнәре 7,8 процентка арткан инде. Әмма шуңа карамастан, ел ахырына инвестицияләрнең 2 процентка кимүе көтелә. Дәүләт финанслауны арттыра, хосусый инвесторлар табан ялтырата дигән сүз бу.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

# ТӘРТИП БУЛСЫН!

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов өлешчә мобилизация мәсьәләләре буенча оператив штабның һәм чакырылыш комиссиясенең уртак утырышын уздырды. Утырышта ярдәм чаралары, хәрбиләрнең көнкүрешенә бәйле сораулар күтәрелде.**

Республиканың хәрби комиссары Сергей Погодин, өлешчә мобилизация нәтиҗәләре турында хисап тотып, районнар белән бергәләп эшләүнең мобилизация бурычларын вакытында үтәргә мөмкинлек бирүен искәртте.

Шулай да тәртип урнаштырасы җирләр дә юк түгел. Татарстан Президенты әйтүенчә, Россия Президенты да хәрби комиссариатлар эшен яңартуның әһәмияте турында билгеләп үтте. «Безгә дә бу эштә тәртип булдырырга кирәк», – диде республика җитәкчесе.

Моннан тыш Рөстәм Миңнеханов хәрбиләрнең җыелу пунктларындагы көнкүреш шартлары мәсьәләсенә тукталды. Мобилизацияләнүчеләр өчен яхшы шартлар тудырылырга тиеш, дип ассызыклады ул.

– Туклану, уңайлы шартлар тудыру кебек мөһим мәсьәләгә игътибар бирүне сорыйм. Бөтен җирдә тәртип булырга тиеш. Тәртипсезлек безне бер дә бизәми. Мондый аңлашылмаучанлыклар булырга тиеш түгел, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Кешеләр белән дә аңлашырга кирәк. Мөрәҗәгать итегез – без бит бу сорауларны хәл итәбез. Оештыру, көнкүреш, хокукый сораулары бар икән – хәл итәбез. Бу – сезнең җитешсезлек кенә түгел, уртак җитешсезлегебез. Без барыбыз да – бер гаилә. Без барыбыз да җаваплы.

Узган атнада Казан танк училищесындагы мобилизацияләнгән хәрбиләр андагы шартлардан зарланып, социаль челтәрләрдә видео таратты. Алар үзләренә чи утын китерүдән, телефон өчен зарядка алу мөмкинлеге булмаудан зарлана. Бу хәлдән соң проблемаларны тиз арада хәл итәргә тырыштылар.

Хәрбиләрнең көнкүреше димәктән, Татарстан Президенты Казан танк училищесындагы мобилизацияләнүчеләрнең җыелу пунктын үзе барып күрде. Рөстәм Миңнеханов палаткалы лагерьда яшәүчеләрнең көнкүреш, туклану шартлары белән танышты. Моннан тыш хәрби өйрәнүләрне күзәтте, ату урынында булды. Соңрак «Казан Экспо» үзәгендәге мобилизацияләнүчеләрнең яшәү шартлары белән дә танышты, полигонда булды.

Хөкүмәт йортында узган утырышта хәрбиләрнең гаиләләренә күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында да сөйләштеләр. Рөстәм Миңнеханов махсус хәрби операция зонасына үз теләге белән китүчеләрнең балаларына 20 мең сум акча түләүне оештырырга кушты.

– Һәр ярдәм чарасы һәр гаиләгә барып җитәргә тиеш. Гаиләләрне кайгыртырга һәм игътибардан калдырмаска кирәк, – диде Президент.

Татарстанда 13 депутат мобилизацияләнгән. Мәгълүм булганча, әлеге депутатлар – Казан, Әлмәт, Менделеевск, Кама Тамагы, Чистай, Актаныш, Саба, Теләче, Баулы, Әгерҗе, Буа, Балык Бистәсе һәм Алексеевск районнарыннан. Аларның берсе – махсус хәрби операция зонасында, тагын җидесе – хәрби хәрәкәтләр барган зонадан ерак түгел урнашкан хәрби частьларда, бишесе Казан танк училищесында әзерлек уза.
Сүз уңаеннан, Дәүләт Советы депутаты Эдуард Шәрәфиев тә үз теләге белән махсус хәрби операциягә китүен социаль челтәрдәге сәхифәсендә хәбәр итте. Ул контракт төзеп киткән. Моңа кадәр Эдуард Шәрәфиев Донбасска гуманитар ярдәм белән берничә тапкыр барган иде инде. «Хәзер, илебезнең мәнфәгатьләрен иңгә-иң торып яклау өчен, бердәм булуыбыз кирәк! Моннан тыш, мин хәрби операция шартларында егетләребезнең чынбарлыктагы ихтыяҗын аңларга ниятлим. Алга таба аларга матди-техник һәм гуманитар ярдәм күрсәтү өчен кирәк бу», – дип язган депутат.

# Кичә уйда, бүген кесәдә

**Ярдәмнең артыгы булмый. Әле күптән түгел генә ике кызына дәүләт тарафыннан 20шәр мең сум пособие алган Елена Мусаткина шулай ди. Бөгелмәдә яшәүче гаилә моннан бер ай элек әтиләрен Ватанны сакларга озаткан.**

– Мобилизациягә эләгүчеләрнең балаларына бер тапкыр 20 мең сум акча бирәчәкләрен ишеткәч, сөендек инде. Соңгы айда чыгымнарыбыз бик күп булды бит. Кызларыбызга кышка кием аласы бар дип борчылып йөри идем. Пособие акчасына балаларны киендереп кайттым, – дип сөенә әни кеше.

Актаныштa яшәүче Гүзәл Шәфидуллина баласына тиешле пособиене октябрь азагында алган.

– Балаларыбызны онытмыйлар, рәхмәт. 19 октябрьдә районның «Игелек» үзәгенә барып, гариза яздым. Үземнең паспорт, баланың туу турында таныклык күчермәсен, счет турында тулы мәгълүмат калдырдым. Сигез көннән соң бу акча күчте. Пособиенең шактый өлешен тотарга өлгердек инде. Сентябрь ае өчен балалар бакчасына, фатир арендасына түләдем, балага киемнәр алдым. 1 октябрьдән кызыбыз балалар бакчасына бушлай йөри башлады, – ди Гүзәл.

Азнакайда яшәүче Зилә Гарипова исә 14 яшьлек улы Исламга тиешле пособие якын арада күчәргә тиеш, дип көтә. Районның социаль яклау идарәсенә гаризаны 24 октябрьдә тапшырган.

– Безне онытмаулары өчен рәхмәт. 20 мең сум аз акча түгел. Иш янына куш булып, ярап куя. Ул акчага улыбызга кышкы киемнәр алырбыз дип торам. Улыбыз бер ай элек түгәрәкләргә дә бушлай йөри башлады. Мәктәптә туклануга ай саен 1200 сум акча түли идек. Мобилизациягә эләгүчеләрнең балалары өчен хәзер анысы да бушлай, – ди Зилә.

Билгеле булганча, Татарстанда әтиләре мобилизациягә эләккән, 18 яше тулмаган балаларга 20шәр мең сум акча бирү турында карар имзаланды. Мобилизацияләнгән кешенең хәрби хезмәткә чакырылган чорда Татарстанда теркәлгән булуы шарт. Әлеге адрес буенча бер тапкыр бирелә торган пособиене алу кагыйдәләрен аңлаткан хат һәм гариза бланклары җибәрелгән. Кәгазьләрне тутырып, яшәү урыны буенча, күрсәтелгән вакыт эчендә Республика матди ярдәм үзәгенең җирле бүлекчәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Үзең белән балаларның туу турында таныклыкларын алу да сорала.

Әгәр дә мобилизацияләнгән ирнең гаиләсе түләүләр хакында хәбәр алмаган икән, ул очракта алар Республиканың матди ярдәм үзәгенә үзләре мөрәҗәгать итәргә тиеш. Әниләре Татарстанда теркәлмәгән икән, ул вакытта аңа ире теркәлгән җирлектәге үзәккә мөрәҗәгать итәргә. Пособие билгеләгәндә баланың әтисен мобилизацияләү хакында мәгълүматлар Татарстанның Хәрби комиссариатыннан алыначак. Шуңа да хәрби комиссариаттан белешмә алып килергә кирәкми.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# Мәктәпләрдә кичен... утлар яна

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Мәрхүм иренең кичен укыган чакларын да искә төшереп: «1964 елда 7 нче сыйныфтан соң булачак ирем Азнакай районының Вахитов совхозында кичке мәктәптә белем алды. Ул вакытта армиядән кайткан егетләрнең күбесе шулай укыды. Бер караганда, кызык та иде. Тик кичен кызлар белән йөрергә вакытлары калмый иде. Мине шушы авылга пионер-вожатый итеп җибәргәннәр иде. Аннан техникумны тәмамлап, Чаллыда КамАЗ төзелешендә наладчик, бригадир булып эшләде», – диде ул.

Кадимчелек заманнары күптән үтсә дә, укуга әллә ни исләре китмәгәннәр хәзер дә бар. Андыйлар, их, нигә мәктәптә яки техникумда ыштан туздырып йөрдем икән, дип үкенә. 22 яшьлек Казан егете Айнур Камалов та шундый хисләр белән яши. Хәзерге вакытта курьер булып эшләүче егет укуын кичке мәктәптә дәвам итәргә ниятли.

– Мәктәптә «4ле» билгеләренә генә укыган идем югыйсә. Шул ук вакытта сәнгать мәктәбен тәмамладым. Рәсемне оста ясыйм, җырлау сәләтем дә бар. Спорт белән дә шөгыльләндем. Тик 9 нчы сыйныфта уку теләге качты. Укытучыларның һаман саен имтиханнар турында сөйләп торуы да туйдырды. Янәсе, тапшыра алмасаң, тагын бер елга утырып калачаксың. Дәрестән сылтау табып, өйгә компьютер уеннары уйнарга кайта идем. Укымас өчен, гел хәйлә эзләдем. Виртуаль дөньяда сине беркем дә гаепләми, – ди Айнур, хаталарын искә төшереп. – Көч-хәл белән 9 нчы сыйныфны тәмамладым. Безнең сыйныфта минем кебек егетләр берничә иде. Техникумга укырга кердем, әмма өченче курстан соң ташладым. Начар малайларга иярдем. Вакытында акылыма килеп, дөрес юлны таптым тагын. Хәзерге вакытта акча да бар, тик дипломым юк. Шул искә төшә дә оят булып китә. Дөрес, укымыйча да яшәп була анысы. Әмма гаилә корып, балаларым туса, нәрсә диярмен? Бу ягы да бар бит аның. Шуңа күрә вакытында укырга кирәк.

Сәрия МИФТАХОВА

**Белгеч фикере**

**Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ,**
**Казан федераль университетының укыту һәм тәрбияләү методологиясе кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре докторы:**

– Теләсә кайсы җәмгыятьтә тулы урта белем яки башлангыч яки урта һөнәри белем бирүне кичке мәктәпләрдән башка оештыру мөмкин түгел. Ул элек тә кирәк булды, хәзер дә кирәк, киләчәктә дә кирәк булачак. Мин студент елларында кичке мәктәптә тарих укыттым. Директор булып эшләгәндә, һәр зур мәктәп базасында кичке мәктәпләр бар иде. Аны һөнәри уку йорты белән бергә оештыра идек. Механизатор, шофер белгечлегенә исә СПТУдан килеп укыталар иде. Татарның бик акыллы мәкале бар: «Син дә – мулла, мин дә – мулла, атка печән кем сала?» Кичке мәктәп – кирәкле әйбер. Әгәр җәмгыятьне хезмәт кешеләре белән тәэмин итәбез дисәк, бу юлны һич онытырга ярамый. Статистикага карасак, яшьләрнең 10–15 процентының дәүләт стандартларына туры китереп укырга мөмкинлеге дә, теләге дә юк. Андыйларга 9 сыйныфка кадәр мәктәптә белем бирсәк, аннары кичке мәктәпләрдә эшләп укый алалар. Белем дә, профессия дә бирү – иң отышлысы. Шушы юл аша үткәрмәсәк, бөтен ялкау, хөрәсән, җинаятьче, кеше хисабына яшәүчеләр шушы төркемдә формалашачак. Бу – чынбарлык, моны беркемнән дә яшереп булмый.

# ЧАЙКАЛМАСЫН КӨЙМӘЛӘР!

## БАЛЫК ТОТУЧЫЛАРНЫҢ КУРКЫНЫЧ САННАРГА ДА, ШТРАФЛАРГА ДА ИСЕ КИТМИ

**Һава торышы көйсезләнгәндә, көймәләре капланып, ел саен 4–8 кеше су корбаны була. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе җитәкчесе урынбасары Юрий Венедиктов хәбәр итте. Белгеч елга буйларында сәяхәт кылырга, балык тотарга яратучыларны сак булырга киңәш итте.**

Быел Татарстанда суда батып үлүчеләр саны узган ел белән чагыштырганда азрак. Әмма саннар барыбер куркыныч. Ел башыннан елга-күлләрдә 76 (былтыр – 9) кешенең гомере өзелгән, шуларның 8е (9) – балалар. Төп сәбәбе – рөхсәт ителмәгән урыннарда су коену. Җәйге челләдә су коенучыларны гына түгел, көймәдә йөзәргә, балык тотарга яратучыларны да аямый елга-күлләр.

– Әгәр коткару жилеты кисәләр, фаҗигаләр азрак булыр иде. Иминлекнең нигезе шул бит, – диде Юрий Венедиктов. Сүз уңаеннан, әлеге кагыйдәне үтәмәүчеләргә 15–20 мең сум күләмендә штраф яный. Йөртүчеләргә дә җәзасы бар.

Быел көймәләр белән бәйле 9 фаҗига теркәлгән. Анда тугыз кешенең гомере өзелгән, бәхеткә, 37сен коткарганнар. Дүрт очрак Минзәлә, Балык Бистәсе районнарында, Казандагы сулыкларда да килеп чыккан. Төп сәбәпләре – көймәләр бәрелешү, бату, анда утырган кешенең суга егылып төшүе. Агыйдел елгасында югалган 39 яшьлек ир-атны коткаручылар 5 көннән соң гына эзләп таптылар. Балыкчылар Актанышка Чиләбедән үк килгән. Алдан билгеләнгән вакытта очрашкач, араларында бер кешенең югалганын ачыклаган. Аның мәетен ярдан 50 метр ераклыкта су төбендә эзләп таптылар.

Татарстанда Иделдә навигация, ягъни суднолар хәрәкәте 24 ноябрьдә тәгәлләнә. Ноябрьнең өченче атнасында боз ката башлар дигән фараз бар. Шуңа күрә Юрий Венедиктов тагын бер кат саклык чаралары турында искә төшерде. Кисәтү балыкчыларга гына түгел, бала-чагага да кагыла.

– Көз көне температура көн саен түбәнәя, дулкыннар көчәя. Хәзерге вакытта резин көймәләр яр буенда балык тотарга гына ярый. Аларны читкә алып куеп, кышкы кармакларны, карчаналарны әзерләгез. Балыкка үзегез генә йөрмәгез. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы сайтына кереп, коткару постларын карап, шул җиргәрәк барып, иминлек кагыйдәләрен саклап тотыгыз, – диде белгеч.

Түбән Камада яшәүче Айрат Гайфетдинов балыкка атнага ике тапкыр йөри. Елгага көймәсен кат-кат тикшермичә чыкмый икән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Минеке – алюминий көймә. Резина белән дә йөриләр. Андыйлар белән бөтен Кама тулган. Әлегә суда тыныч. Навигация беткәч, маякларны алгач, көчле җилләрдә куркыныч. Балыкчылар боз катканчы да, каткач та йөри. Алар бу шөгыль белән авыру инде, туктатып булмый. Ә балык бетми, һаман бар ул, – ди Айрат. – Коткару жилетымны киям, кирәкле әйберләр бармы, көймәгә су кермиме дип, барысын да тикшереп чыгам. Һава торышына да карамыйча булмый. Жилет кимәсәң – штраф. Ә югалучыларның күбесе – исерекләр. Аракы балыкчының башына җитәргә мөмкин.

Сәрия МИФТАХОВА

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясындагы 1 өлешенең егерме тугызынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«лицензия – юридик зат яисә индивидуаль эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең конкрет төрен (эшчәнлекнең лицензияләнә торган төренә кергән эшләр башкару, хезмәт күрсәтү) гамәлгә ашыру хокукына лицензияләр реестрында язма белән раслана торган махсус рөхсәт;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 02 ноябрь, № 74-ТРЗ

---

## «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2022 ел, 8 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешендәге 13 пунктында «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең» сүзләрен «гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең» сүзләренә алмаштырырга;

2) 21 статьяның 1 пунктында «, шулай ук сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтләр башкаручы җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 23 статьяда «, сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтләр башкаручы җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 02 ноябрь, № 75-ТРЗ

---

## Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирләрнең һәм җир кишәрлекләренең хокукый режимы, аларның теге яисә бу җир категориясенә керүеннән һәм рөхсәт ителгән файдалануыннан чыгып, федераль законнар нигезендә билгеләнә.»;

2) 12 статьяның 7 пунктындагы 1 пунктчасында «бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү» сүзләрен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнүе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 32 статьяның 3 пунктындагы 1 пунктчасында «бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләренә алмаштырырга;

4) $32^{1}$ статьяда:

а) 2 пунктта «бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен үзләренә җир кишәрлеге бирү йә мондый гражданнар милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлекләрен» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен үзләренә җир кишәрлеге бирү йә мондый гражданнар милкендә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлеген» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 пунктның беренче абзацында «бакчачылык, яшелчәчелек» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктның беренче абзацында «(йорт янындагы җир кишәрлеге),» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

г) 10 пунктның беренче абзацында «(йорт янындагы җир кишәрлеге),» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

д) 11 пунктның беренче абзацында «(йорт янындагы җир кишәрлеге),» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

е) 12 пунктның беренче абзацында «(йорт янындагы җир кишәрлеге),» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 02 ноябрь, № 76-ТРЗ

---

## «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлешнең 1 пунктындагы бишенче абзацында «эшсез гражданнарга һәм» сүзләреннән соң «яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга,» сүзләрен, «эшсез гражданнарга» сүзләреннән соң «һәм яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

2) $3^{1}$ өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы хезмәт базары үзенчәлекләрен һәм эш эзләүче, эшли башларга әзер булучы һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнар тарафыннан буш эш урыннарын һәм вакантлы вазыйфаларны биләү мөмкинлеген исәпкә алып, дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткәрләр җәлеп ителми торган вазыйфалар, һөнәрләр, белгечлекләр исемлеген расларга хокуклы.»;

3) $3^{3}$ өлешнең 1 пунктында «эшсез гражданнарга» сүзләреннән соң «, яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

4) 4 өлешнең 6 пунктындагы уникенче абзацында «эшсез гражданнарга һәм» сүзләреннән соң «яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга,» сүзләрен, «эшсез гражданнарга» сүзләреннән соң «һәм яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 02 ноябрь, № 77-ТРЗ

---

## Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 27 статьяның 5 өлешендә «бер ел эчендә» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Граждан кодексының $173^{1}$ статьясы кагыйдәләре буенча» сүзләрен өстәргә;

2) 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^{1}$ өлеш өстәргә:

«$1^{1}$. Бала тууны рәсмиләштерү кенәгәсендәге баланың атасы турында әлеге Кодексның 42 статьясындагы 2 өлеше нигезендә башкарылган язма шулай ук баланың атасы булып язылган затның варисы таләбе буенча суд тәртибендә дәгъваланырга мөмкин. Күрсәтелгән өлешнең нигезләмәләре бозылган очракта, шул исәптән мондый язма ялган документлар нигезендә йә ата булуы судтан тыш тәртиптә билгеләнгән затның ирекле ихтыяр белдерүеннән башка башкарылган булса, тиешле таләп канәгатьләндерелергә мөмкин.»;

3) 147 статьяның 5 өлешендә «белем бирү оешмасында» сүзләрен «оешмада» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 02 ноябрь, № 78-ТРЗ

---

## «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2010 елның 24 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 10, № 11; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланалар, анда, гарызнамәне җибәреп була торган электрон почта адресын күрсәтеп, үзләренең рәсми сайтларын булдыралар, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның $10^{6}$ статьясында каралган таләпләргә туры килә торган мәгълүмат системаларында һәм (яисә) электрон хисаплау машиналары өчен программаларда рәсми битләрен булдыралар.»;

2) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 02 ноябрь, № 79-ТРЗ

---

## Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.19 һәм 2.20 статьялар өстәргә:

«2.19 статья. **Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү**

Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәгән, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп иткән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салына.

2.20 статья. **Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша куллануга җәлеп итү**

Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сатуны чикләүне үтәмәгән, шулай ук балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша куллануга җәлеп иткән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.18» саннарын «2.11 – 2.20» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяның 14 өлешендә «2.17,» саннарыннан соң «2.19, 2.20,» саннарын өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), аңа «2.17,» саннарыннан соң «2.19, 2.20,» саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 10; 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «(алга таба – Федераль закон)» сүзләреннән соң «, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктлар өстәргә:

«6) алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләр – «Алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләр. Гомуми техник шартлар» ГОСТ Р 52844-2007 Россия Федерациясе Милли стандартында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган эчемлекләр;

7) гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарлар – сыекландырылган углеводород газ контейнеры булган кабызгычлар, шулай ук көнкүреш җиһазларын эшләтү, кабызгычларга газ салу өчен кулланыла торган сыекландырылган углеводород газы кергән баллоннар.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $7^{1}$ һәм $7^{2}$ статьялар өстәргә:

«$7^{1}$ статья. **Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләү һәм балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итүне тыю**

1. Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сату рөхсәт ителми.

2. Балигъ булмаганнарны алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне куллануга алар өчен сатып алу яисә аларга мондый эчемлекләрне тапшыру, аларны куллану тәкъдиме яисә таләбе юлы белән җәлеп итү тыела.

$7^{2}$ статья. **Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сатуны чикләү һәм балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша куллануга җәлеп итүне тыю**

1. Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сату рөхсәт ителми.

2. Балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша аны куллану тәкъдиме яисә таләбе юлы белән җәлеп итү тыела.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 02 ноябрь,№ 80-ТРЗ

---

## «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта «кече һәм урта» сүзләрен «кече яисә урта» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кече яисә урта эшкуарлык субъекты ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозган дип танылган вакыттан бер елдан кимрәк вакыт үткән булса, кече яисә урта эшкуарлык субъектының ярдәм күрсәткән орган яисә оешма тарафыннан мондый хокук бозуны бетерүгә билгеләнгән срокны үтәве шартында аның мондый хокук бозуны элегрәк бетерү очрагыннан тыш, ә ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозу ярдәм күрсәтү чараларыннан максатчан файдаланмауга яисә дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыруга бәйле булганда, кече яисә урта эшкуарлык субъекты мондый хокук бозуны кылган дип танылган вакыттан өч елдан кимрәк вакыт үткән булса. Әлеге пунктта каралган нигезләмәләр ярдәм күрсәткән орган яисә оешма тарафыннан кече яисә урта эшкуарлык субъектының ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозулары ачыкланган ярдәм күрсәтү төрләренә кагыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2022 елның 26 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 02 ноябрь, № 81-ТРЗ

---

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 2022 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен бирү турында

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Тимирясова Асия Виталий кызына – «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе ректорына;

2) Туманов Дмитрий Александровичка – Татарстан Республикасының «Созвездие-Йолдызлык» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы генераль директорына;

3) Шекуров Руслан Петровичка – «Донор-Сёрч» донорлыкны үстерү коммерциячел булмаган партнёрлыгы ассоциациясе директорына;

4) «Россия студентлар отрядлары» бөтенроссия яшьләр иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә;

5) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Әфганстандагы һәм Төньяк Кавказдагы сугыш хәрәкәтләре ветераннарының җирле иҗтимагый оешмасына;

6) «Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасына;

7) «АЛЬПАРИ» хәйрия фондына;

8) «Татарстан энҗесе» инвалидларга ярдәм итү төбәк иҗтимагый оешмасына.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль,
2022 ел, 02 ноябрь,
N ПУ–782

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Кулон» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Фәхретдинов** Альберт Шамил улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Ак Барс» судонолар төзү корпорациясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – аппарат җитәкчесе **Александров** Дмитрий Валентинович, яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсе идарәсе рәисе урынбасары **Мәннанов** Әнәс Гарифҗан улы, хореография сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Чаллы сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең хореография бүлекчәсе укытучысы **Побужанская** Ольга Павловна, мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе директоры **Сәүбәнова** Раушания Кыяметдин кызы, республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Казан шәһәренең «Ракета» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Севрюгин** Олег Әнвәр улы, мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авылының «Каен» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячесе **Тимиряева** Людмила Борисовна, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен «К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Хәсәнова** Әлфия Якуп кызы, республикада китапханә эшен үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры урынбасары **Чернова** Диана Юрьевна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

**Казан шәһәре Идел буе районының «Россия Герое Д.Р. Гыйлемханов исемендәге 42 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе коллективына**, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе **Дәүләтшин** Марс Мирза улына, «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең халык иҗатын үстерү бүлеге мөдире **Александров** Павел Андреевичка, «Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесенең балалар һәм яшьләр белән эшләү бүлеге мөдире **Кадыйров** Тимур Рәфкать улына, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе урынбасары – бюджет бүлеге башлыгы **Билалова** Алсу Әмир кызына, Татарстан Республикасы прокуратурасының планлаштыру, хезмәт, финанслау, бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге баш белгече **Галиуллина** Дилбәр Ривкать кызына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы **Нуриев** Илшат Габделфәрт улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

# КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе, КПССның Чаллы шәһәре Автозавод райкомы беренче секретаре, КПССның Алабуга шәһәр комитеты беренче секретаре

**НУРМӨХӘММӘТОВ**
**Наил Сәет улы**

вакытсыз вафат булу сәбәпле, аның туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын, югалту ачысын уртаклаша. Бу авыр минутларда сезнең белән бергә кайгырабыз.

---

Утеряно приложение к диплому 16 ПА 0001454 о среднем профессиональном образовании (регистрационный номер 194 от 28 мая 2010 года), выданному на имя Бадриевой Дилюзи Марселевны ГАОУ среднего профессионального образования «Казанский педагогический колледж».

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

# БЕЗНЕҢ ШӘЕХ

Татар матбугатының шәехе, солтаны, алтын баганасы, 50 елдан артык гомерен «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга», бигрәк тә чирек гасырга якынын «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасында, армый-талмый, дәртләнеп, кайнарланып, яратып, сөенеп хезмәт иткән, 17 ел рәттән «Татар мөселман календаре» чыгарып килгән Миншәех Харис улы Зәбировның Аллаһ хозурына мәңгелеккә күченүенә унөч елдан артып китте. Быел ноябрь аенда 90 яшь тулган булыр иде. Ул үзеннән соң бик күп изгелекләр, яхшы эшләр, китаплар, календарьлар калдырып китте. Ул кешеләр өчен яшәде, кешеләр дә аны ярата иде.

Биек тау башында туган ул, паспортында да Ош шәһәре дип язылган иде. Бишенче дистәне ваклаган Харис абзый озак көттергән улына исемне бик алдан әзерли. Тимершәех дип куялар. Ни хикмәт буладыр инде, баланың сулышы кысыла, суларга һава җитми. Кыш җитте дип тормыйлар, җәйне дә көтмиләр, язгы дәрья суларында ага-ага туган авылга – Лениногорск районы Сарабиккол авылына алып кайтып, туган як мулласыннан колагына Миншәех дип кычкырталар. Ярый әле ул чакларда «шәех»нең нинди мәгънә аңлатканын белмиләр. Бер очракта ул юлбашчы дигәнне белдерә. Икенче урында «шәех» сүзе дәрәҗәне аңлата һәм ислам диненә хезмәт иткән зур шәхес, акыл иясе дип билгеләмә бирелә.

**Миншәех Зәбировның (фоторәсемдә уңнан икенче) «Социалистик Татарстан»да (хәзерге «Ватаным Татарстан») эшләгән еллары. Степан Дементьев, Госман Гомәров, Асия Авзалова белән редакциягә алынган хатлар турында фикерләшү мизгеле**

Ул үзе әнә шушы серле исеменә гомере буена тугры булып яшәде, аны акларга тырышты. Кечкенәдән нык, зур башлы, таза, матур, көчле булгандыр ул. 1932 елда туса да, бик тиз үсә, 1941 елда башланган сугышның буеннан-буена, үгез җигеп, колхозда эшли. Тыл батыры була, орден, медальләргә күмелә. Сугыш бетүен бетә ул, җиңүчеләр дә кайта, тилмереп көткән җиңеллек кенә килми. Халыкның тормыш хәле бер дә яхшырмый. Юлбашчылык шунда чагыла. Сарабиккол үсмерләре Сталинга каршы «Ленин юлыннан» дигән «банда» оештыра. Тавышы Мәскәүнең үзенә үк ишетелә. Мәктәптә бер генә укытучыны да калдырмыйлар. Дәһшәт район җитәкчеләренә дә кагыла. Луиз Хафизов, Искәндәр Зәбиров һәм Миншәех Зәбиров шул гарасаттан да исән-сау чыга. Дөрес, бу вакыйга аларны гомер буена озата бара, вакыт-вакыт сиздерми генә тез астына китереп тибә. Шөкер, егетләр нык, берәү дә егылмый, һәрберсе үз өлкәсендә кирәк. Ул чакта да Шәех абый – журналист, листовкалар язучы, таратучы. Шулай итеп ул 14–15 яшьтә иптәшләре тарафыннан билгеләп куелган һөнәргә гомере буена тугры булып кала. Алай гына да түгел, татар матбугатының солтаны, шәехе була. Бу юлга кереп китмәсә, ул, һичшиксез, язучы булыр иде. Язучы Роза апа Хафизова белән бер чишмә суын эчә ул. Сылубикә әбинең төннәр буена укыган китапларын – Йосыф кыйссасын, Сак-Сок бәетен, Коръән тыңлап үсәләр. Шуннан соң да инде син шигырь-поэма, пьеса язмый түзеп кара. Яза ул аларны. Әнә шул халыкны бәхетле итәсе килү комачаулый. Юк, киресенчә, этәргеч бирә. Төзелеш институтына да керә ул, сызым сызарга да өйрәнә. Өйләнеч булса да, Казан дәүләт университетына укырга керә. Әле алай гына да түгел, Мәскәүдә Үзәк Комитетның партия мәктәбен кызыл диплом белән бетерә, аспирантурага да кереп кайта.

Шуннан соң инде ул матбугат дәрьясына чума. «Яшь ленинчы»да эшли, «Татарстан яшьләре»ндә мөхәррир, «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга» газеталарын оештыручыларның берсе була. Шулай да «Социалистик Татарстан» газетасында эшләгән еллары – иң бәхетле елларыдыр.

Мөхәррире – олпат, олы йөрәкле Шәмси ага Хамматов дилбегәне, ышанып, тулысынча аңа тапшыра. Яхшы кешенең кучеры да үзе кебек булырга тиеш. Миңа 10 елга якын «Социалистик Татарстан» газетасында Миншәех Харис улы кул астында эшләү насыйп булды. Аның эш бүлмәсе, кайсы гына газетада булса да, һәрвакыт ачык, һәрвакыт штаб кебек кайнап тора иде. Һәрвакыт аның янына яшь журналистлар җыелыр иде. Киң күңелле, ачык йөзле кеше иде. Һәрвакыт, кайда гына, нәрсә генә сөйләшсә дә, гомер буе сүзе шул газеталарга барып тоташа иде. Ә газета матур, бай, эчтәлекле чыккач, ничек сөенә иде?! Нәкъ менә шул елларда, бигрәк тә язучылар корылтаенда газетаны тәнкыйтьләгәч, әдәбият-сәнгатьне яктырткан «Әллүки» кушымтасы чыга башлады. Ул аңа да бик сөенде.

Әлбәттә, аның иң зур эше «Татар мөселман календаре»н чыгаруы булгандыр. Аны бит ул уйлап тапты, ул эшләде. Ул гомере буе шуңа әзерләнгән. Әйтергә генә җиңел, әле бит рәхәтләнеп өйрәнергә намаз китабы гына да юк чакта халкыбызны намазга өндәгән, иманга чакырган, Коръән укырга өйрәткән гаҗәеп дәрәҗәдә бай эчтәлекле календарьның атасы, язучысы, төзүчесе, якты нурга манучысы, газиз халкыбызга илтеп җиткерүчесе дә Миншәех Зәбиров иде.

Сез аны, сөендереп, «Фәния календаре» дип йөргәч тә, ул бит аныкы иде. Аны ул уйлап тапты да миңа бүләк итте, ул мине бик ярата иде. Ул бөтен кешене бик ярата иде. Аның бер кеше турында да начар сүз әйткәне булмады, ул гайбәт сөйләми, сөйләтми дә иде. Ул эш ярата иде. Юк кына нәрсәләрдән дә кызык эзли, таба, шуңа сөенә иде. Соңгы елларда ул алмагачлар утыртты, бакча үстерде, чәчәкләр ярата иде. Өй тирәбезгә өч төрле сирень генә утыртты, барысы да шау чәчәктә. Соңгы елларда чуар тавыклар үстерде, чебиләр чыгартты. Шуларга сөенде.

Шәех абый дини китаплар, Коръән эченә чумып, эчендә йөзеп, рәхәтләнеп яши, эшли иде. Халкыбызга дөнья һәм ахирәт кыйммәтләрен җиткерергә тырыша иде.

Аның җаныннан чыккан изге теләкләре, гыйбрәтле сүзләре кешеләргә барып җитә, бик күп рәхмәт хатлары килә, ул аларны бик рәхәтләнеп укый, календаребызны укыганга, яратканга бик сөенә иде. Кешеләр үзләре дә киләләр иде. Бервакыт Уфадан Шәех абыйның университет сабакташы Шәүрә апа килде.

– Шәех, сиңа имтиханга килдем, тыңла әле мине, – диде. Бик матур бер хатирә булып калды бу. Бөтен кеше йоклап беткәч, Шәүрә апа госел коенып чыкты, матур күлмәк киде һәм «Йәсин» укыды.

– Сезнең календарь буенча өйрәндем, шуның буенча намазга да бастым, рәхмәт сиңа, Шәех, укуым дөресме? – диде.

– Ярый, ярый, – диде Шәех абый.

Һәр икесенең йөзе нур белән тулган иде, Шәех абыйның бите буйлап яшь бөртекләре тәгәрәде.

Бу мизгелдә алар икесе дә бик матур иде. Ә миңа сигезенче дистәне ваклап йөргән югары белемле, хәтерле, акыллы фикерле кешеләргә карап утыру, төн уртасында кунак итү бик рәхәт иде.

Мондый очрашулар бездә бик еш булды, ул кунаклар ярата, үзе сөйли, кунакларны тыңлый иде. Шәех абый әллә ниләр эшләп калдырган инде. Хәтта сүзлек тә төзегән. Телебезгә, матбугатка соңгы елларда бик күп сүзләр керде. Шуларның бик күп төрле язылышына үртәлә иде. Хәрәм, харам, хәрам, харәм – кайсы дөрес? Соңгы арада күңеле сизгән шул инде, гел эш, эш, диде.

Вафаты белән дә сабак биреп, китап язарлык эшләр, гыйбрәтләр калдырып, безне сискәндереп, елмаеп, мәңгелеккә күченде. «Ватаным Татарстан» газетасының (газета төрле елларда, төрле исем белән нәшер ителде) чыга башлавына 105 ел туларга ярты ел чамасы калган бу көннәрдә Шәех абыйны искә алуыбыз да юкка гына түгел! Хәтеребездә, күңелебездә ул – безнең Шәех!

Шәехҗан Фәния ХУҖАХМӘТ

## СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАЛАРЫ

Балачагым – ачлык-ялангачлык әледән-әле хәтеремә төшеп тинтерәтә. Көнне төнгә ялгап, яшьлеген колхоз эшенә багышлаган Каенсар авылындагы дустым Рәеф Шакиров та ул елларны күз яшьләре белән искә ала. Күп кенә чордашларыбыз кебек үк ул да әтисез үскән. Әтисе сугыштан кайтмаган. «14 яшемдә «ДТ» тракторында плугарь идем инде мин, – дип сөйләгәне хәтердә, – аңарчы терлек көттем. Аннан комбайнга утырдым, «ДТ-73» тракторында да эшләдем. Эшләмәгән эшем калмады. Басуларда да мин аяк басмаган, трактор белән йөрмәгән җир калдымы икән? Миңа бит кайсы басуда эшләргә кирәклеген әйтүче булмады диярлек, үзем барып карый идем дә, басу өлгергәч, эшкә керешә идем. Тракторда бер ремонтсыз ун елдан артык эшләдем».

Сугыш чоры балалары менә шундый инде алар.

Рафаил БӘЙРӘМОВ

## *«Әтиегез бүләге»*

Сугыш чоры балалары, тыл ветераннары турында укыгач, фильмнар карагач, аларның гомерләре сагынып сөйләрлек түгел шул дигән нәтиҗәгә киләсең.

Сезгә ирем – балаларымның әтисе Рафаил Хәмидуллин сөйләгәннәрне искә төшереп язарга булдым.

Ватан сугышы башлангач, әтиләре Вәли сугышка китә. «Исән-сау кайтырбыз, Алла боерса, балаларны сакла», – дип юлга кузгала ул. Ләкин аңа әйләнеп кайту насыйп булмый.

Алар гаиләдә ике бала: апасы Флүрәгә – 7, Рафаилгә 1,5 яшь була. Шулай итеп, әтисез көннәр башлана. Ә балалар һаман әтиләрен көтә. 1942 елның 4 июлендә «Батырларча һәлак булды» дигән хәбәре килгәч, балалар: «Әтидән хат килде», – дип шатланалар, хатның эчтәлеген аңламыйлар шул… Хат әле дә Хәтер китабы эчендә саклана.

Сугыш беткәч, авылга солдатлар кайта башлый. Ә аларның әтиләре һаман да юк, күренми. Күрше Габдулла абый кайткач, кечкенә Рафаил: «Әүхәтнең әтисе кайтты, аңа мин дә «әти» дип дәшим әле», – дип елап, өйгә керә. Әнисе, күз яшьләрен сөртеп, апасы белән икесен дә кочагына ала да: «Балакайларым, кайта әтиегез, кайта», – дип юата. Бу көнне генә түгел, озак еллар шулай тынычландыра ул газизләрен.

«Әтисез үсүнең авырлыгын үзе кичергән кеше генә аңлар. Авылда әтиләре яу кырында ятып калганнар күп иде. Дус һәм тату булдык. Мәктәптә черек бәрәңгене дә бүлеп ашадык. Өс-башларыбыз начар, әтиле балаларныкы белән чагыштырырлык түгел. Әни сыер асрады. Апа белән әнигә булыша идек. Шуңа күрә бик ачка интекмәдек», – дип сөйли иде Рафаил.

Мин – Керәле авылы кызы. Ә 1968 елда бу йортка килен булып төштем. Башта балалар бакчасында эшләп, соңыннан укытучы булсам, Рафаил колхозда төрле тармакта хезмәт куйды. Бик тырыш иде…

Җиңүнең 30 еллыгына әнигә – каенанам Хәбибҗамалга – өч метр штапель тукыма бүләк иттеләр. Аның: «Әтиегез бүләге», – дип, тукыманы кулыннан төшермичә елаганы әле дә истә. Аңа күлмәк тегеп бирдем. Миңа һәрвакыт: «Кызым, кул белән генә ю, машинага сала күрмә, машина тиз туздыра», – дип әйтеп килде. Ул кушканча эшләдем.

Рафаил белән 51 ел гомер кичердек. Аллага шөкер, өч ул үстереп, өч улга, өч киленгә әти-әни, җиде оныкка әби-бабай булдык. Балаларыбызның рәхәтен, оныкларыбызның сөенечен күрергә Ходай насыйп итте. Рафаил дә юк инде, урыны оҗмахта булсын. Илләребезгә тынычлык телим, балалар әти-әниләре тәрбиясендә шатланып үссеннәр, һәр туган көнгә куанып яшик.

Флера ХӘМИДУЛЛИНА.
Кама Тамагы

# «ШАЯН ЧӘКӘН» КЫЙССАСЫ

Илленче елларда Н.Хрущев инициативасы белән илдә башланган кукуруз эпопеясе әле дә дәвам итә. Элек аны «басулар патшасы» – «королева полей» дип йөртәләр. Татарстанда бу культура шактый мәйданнарда игелә.

Яшел массасы терлек азыгы буларак киң кулланыла, ә тиз өлгерә торган сортларының чәкәннәреннән бөртекле кукуруз алына. Кукуруз азыктөлек сәнәгатендә төрле ризыклар, эчемлекләр әзерләгәндә файдаланыла. 1970 нче елларда Казан сыра заводы махсус технология белән кукуруз чималын кулланып, алкогольсез газлы эчемлек эшләп чыгарды.

Завод технологлары бу яңа эчемлекнең сыйфатлы һәм ләззәтле булуына иреште, аны күпләп чыгару җайга салынды.

Продукция шампан хәмере салына торган шешәләргә тутырылып, нык бөке белән ябыла иде. Сәүдәгә чыгару өчен аңа исем кушарга кирәк. Завод җитәкчеләре эчемлекне татарча атарга ниятли, тик кулланучыга ошарлык исем таба алмыйлар. Бер акыллысы тәкъдим итә: «Әйдәгез, Татарстан китап нәшриятына мөрәҗәгать итик, бәлки язучылар ярдәм итәр?» Ике хезмәткәр, бер тартма эчемлек алып, Бауман урамындагы Матбугат йортына килә. Нәшрият директоры Гарәф ага Шәрәфетдинов аларны кадрлар бүлеге җитәкчесе Гөлшат Зәйнашева янына җибәрә, ул ярдәм итәр, ди. Гозерне игътибар белән тыңлагач, Гөлшат апа мәсьәләне үзе хәл итәргә була.

vk.com

«Шешәне ачып күрсәтегез әле!» Тыгыз бөкене ачуга эчемлек ургылып бәреп чыга, ярый әле завод хезмәткәре аны кулындагы бокалга юнәлтә.

Гөлшат апа берничә минут уйлана, ә кунаклар аның күзенә карап, сүзен көтә. Шагыйрә бу гаҗәеп эчемлекне «Шаян чәкән» дип атарга киңәш итә.

Бу матур, эчтәлекле исем завод хезмәткәрләренә ошый, алар бик канәгать булып, Гөлшат Зәйнашевага рәхмәтләрен әйтеп, эчемлекләрен нәшрият коллективына бүләк итеп китәләр. Сусаганны баса торган, газлы, тәмле бу эчемлекне завод берничә ел дәвамында 100 мең декалитр эшләп чыгарган. Сәүдә оешмалары аны җәйнең эссе айларында бик теләп кабул иткән, чөнки ул бик тиз сатылып беткән. Шәхсән мин үзем «Шаян чәкән» тарихын Гөлшат апа сөйләвеннән беләм һәм газета укучыларына да җиткерәсем килде. Ул популяр эчемлекнең тәме, ләззәте һаман истә, бәясе дә кыйммәт булмагач, без аны ярата идек.

Сүз уңаеннан, нәселебезнең «йөзек кашы», татар халкы мәхәббәте һәм Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, мәшһүр язучы Гөлшат апабыз Зәйнашеваның гаҗәеп образлы фикер иясе булуын әйтим әле.

Күренекле шәхесләр, төрле вазгыять, туган илгә мәхәббәт һ.б. аңлаешлы, үтемле тасвирлау, эчтәлеген тулырак ачыклау максатыннан, шагыйрә оригиналь, күркәм атамалар уйлап таба, аларны әсәрләрендә, иҗатында уңышлы куллана иде. Мәсәлән, мәшһүр композитор Сара Садыйкованы ул «калфаклы сандугач» дип атады, олылады. «Кояш гомере» (җыр), «Бәхет кошым» (пьеса), «Сипкелле-сөйкемле» (кыз бала), «Гөләни» (әби), «Ясалма мыек» (җыр), «Гөлбакча», «Китмә, сандугач» (патриотизм) һ.б. күп терминнар авторы ул Гөлшат Зәйнашева.

«Шаян чәкән» заманы тарихта калып, инде күп еллар үткәч, бу гыйбрәтле кыйсса исемә төште. Хакимиятнең бүгенге сәясәте дә моңа сәбәпче булды, күрәсең. Хәзер чит илләрдән кертелә торган продукцияне үзебездә җитештерү бурычы куелды. Төрле эчемлекләр эшләп чыгаручы фирмалар Татарстанда шактый. «Шаян чәкән»не яңадан чыгаручы табылмасмы? Аңа ихтыяҗ күп булачагына иманым камил. Республикабызга, бигрәк тә Казанга меңнәрчә турист агыла, аларны һәм халкыбызны «Шаян чәкән» эчемлеге белән сыйласак, безнең абруй тагын да артачак бит!

Икътисад күзлегеннән карасак, бу эчемлекне җитештерүче һичшиксез табышлы, ә кулланучы ачышлы һәм канәгать булачак!

Марс ГАИТОВ,
хезмәт ветераны

# Яшьлегемә кайтыр идем…

Авыл баласы булуым белән бәхетле мин. Шуның өстенә дала киңлегендә туган бала: урмансыз-куаксыз, иксез-чиксез дала киңлегендә үстем. Дала кешесе горур була торгандыр. Безнең борынгы бабайлар да бит дала киңлегендә яшәгән, аны үз иткән. Урман, ни әйтсәң дә, кешенең күрү мөмкинлеген, офыгын чикли. Ә дала исә бик киң, алга карап, ерак офыкларны иңлисең.

Туган авылым – Чүпрәле төбәгендәге Кече Чынлы – минем өчен йөрәккә якын, кадерле. Авыл халкының үткәне, тарихы, мәдәнияте белән кызыксынам. Үткәннәрне барлыйм. Урмансыз булса да, туган авылымның һавасы бик чиста, саф.

Балачагым истәлеге булып сәгать саклана. Текелдәве белән ул мине сискәндерә иде. Аның калай битендә Шишкинның урман аюлары сурәтләнгән. Шул инде мине, сабый баланы, сискәндергәндер. Кайвакыт сәгать текелдәвеннән куркып кычкырып та җибәргәли идем. Тик әни мине бик тиз тынычландыра иде.

Күрше Сәрби әбинең һәм башка күршеләрнең «Кич утыру»га керүләре дә хәтеремдә уелып калган. Аларның әңгәмәбәхәсләре, мөнәҗәт әйтүләре, мәкаль-әйтемнәре киләчәгемә тәрәзә ачты.

«Аулак өйләр» дә үзенә күрә бер тәрбия чарасы иде. Авыл халкы бездә олы кешене «әбзәй» дип атап йөртә. Ул заманда күршебез Зәйдулла әбзәйнең өе чагыштырмача зур иде, «аулак өй» күп очракта шуларда уза. Без – бала-чага да шунда инде. Егетләр аулакка гармун уйнатып килеп керде. Ялтыравыклы галошлы, кайтарма кунычлы киез итекләрдән. Шундый гадәт: егетләр, бию башланганчы, кызларны җырлата. Җырчы кыз уртага чыгып утыра, аның як-ягына баскан кызлар җырчының авыз тирәсен чигүле кулъяулык белән каплап торалар. Соңрак аңладым: бу чара җырчыны егетләр алдында читенсенүдән, оялудан саклау өчен икән. Егетләр бер-бер артлы кызларны җырларга чакыра. Шуннан соң инде гармунчы егет уйнап җибәрә, берәрсе бии башлый, үзенә ошаган кыз каршына килеп, шап иттереп, идәнгә китереп баса.

Биючеләр сафы ишәя тора, шуннан соң инде «Көлтә җыю» – егет-кызларның култыклашып әйләнүләре башлана. Аның да текәрәге – «Утын кисү» дип аталган бию өлеше бик озакка сузыла, кайберәүләр арып-талып, үз урыннарына барып утыра. Җыр һәм бию барыбер тынмый.

Зәйдулла әбзәйдәге аулакка яңа гына өйләнешкән парлар да килеп керде. Рәхәтләнеп күңел ачтылар да кайтырга җыена башладылар: яшь хатыннар, ирләренең киемнәрен чөйдән алып, аларның кулларына тоттырды, кияргә дә булыштылар. Киләчәктә мине дә шундый рәхәтлек көтә икән, дип уйлап куйдым.

Авылыбыз тирәсендә урман булмау (агачны еракта кайтару мөмкинлеге дә юк) йорт төзүдә табигый материалларны файдалануга этәрә иде. Чынлы елгасы язгы ташу чорында бик күп ләмле утырма – дуен калдыра. Авыл халкы, өмә ясап, шул дуенны көрәкләр белән йомшарта, аңа тагын салам, су өстиләр һәм атлар тиешле дәрәҗәгә җиткергәнче таптыйлар. Аннан өмәгә килүчеләр шул дуеннарны тактадан эшләнгән аерым формаларга тутырып тыгызлый. Шуннан инде салам кирпечләр – төзелеш материаллары барлыкка килә. Авылыбызда «дуен кирпече»ннән салынган, зур булмаган өйләр байтак иде.

Чынлы елгасының дуены киндер, кәбестә һәм башка культуралар үстерергә дә булышты. Киндерне авыл халкы «киндераш» дип атап йөртә иде. Заманында әлеге культура безнең колхозның аерым бер тармагы булып та исәпләнде. Киндерашның сабагыннан сүс алалар иде. Кайбер хуҗалыкларда аның орлыгын киледә төеп, май алганнарын да хәтерлим. Киндерашны кул белән тамырыннан йолкып алганнары да истә.

Бәрәңге, һәркайдагыча, бездә дә төп яшәү чыганагы, алыштыргысыз ризык булды. Ул заманада колорадо коңгызы кебек корткычлар да юк иде әле, аны игү дә җайлы булды. Юкка гына халкыбыз: «Үз илемдә ямьле миңа бәрәңге бакчасы да», – дип җырламыйдыр инде.

…Мин – әти-әниемнән мәхрүм калган ятим бала. Мине тудырган әнием Миңҗиһан җиде айлык вакытымда тәрбиягә биргән, әтием башка хатын белән гаилә корган булган. Мине тәрбиягә алган Бибинур белән Нурулланың үз балалары булмаган. Миңа алар әти-әни булды.

Миңа тормыш бүләк иткән әниемнең әнисе Нуриҗамал әбием белән сөйләшеп-серләшеп утырырга ярата идем. Ул үзенең яшь чагында уздырылган бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр, йолалар турында бик еш искә алды, сөйләгәндә йөзе тагын да ягымлылана, күзләре яна, тавышы көрәя. Күңелле, бик күңелле итеп яшәргә тырышкан өлкәннәребез. Заманында тәртип бозулар, хәтта самогон чире дә булмаган. Ислам дине халыкны үз кысасында тоткан.

Әбиемнең: «Халыкның бер-берсе белән аралашмавы, туган-тумачалар белән элемтәдә тормавы борчый мине. Үзара элемтәдә булу авыр сугыш елларын да җиңелрәк кичерергә ярдәм итте, күңелләрне җылытты, өметләрне өзмәскә булышты», – диюе әле дә колак төбендә.

Вакыт-вакыт миннән: «Яшьлегеңә кайтыр идеңме?» – дип сорыйлар. Кайтыр идем. Яшьлегем мине хезмәткә өйрәтте, тирә-юньдәгеләргә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләде. Тормышта үз урынымны таптым һәм халкыма хезмәт иттем. Хәзерге яшьләргә дә балачакларын сагынып искә алырлык булсын иде.

Җәүдәт ХӨСӘЕНОВ,
педагогика фәннәре докторы

### 101 ЯШЬЛЕК САМРА БИКМЕЕВА:

# «СУГЫШ БЕЗНЕ АЯМАДЫ»

Җиңүчеләр

**Дүрт ел буена Бөек Ватан сугышы юлларын үткән, Берлинга кадәр барып җиткән Самра Бикмеева турындагы «үтә яшерен» тамгасы белән билгеләнгән серләрне без узган ел, аңа 100 яшь тулгач кына белдек. Дөресрәге, ул, юбилей белән котларга килгән Татарстан Президенты белән гәпләшә торгач, ничектер ачылып китәргә булган. Рөстәм Миңнеханов бу батыр милләттәшебез турында китап язарга кирәк дигән фикергә килә.**

Бер ел буена Самра апаның сөйләгәннәрен тыңлаганнан соң, журналист Татьяна Вафина бу фикерне тормышка ашыра. Китап «Красивая» дип атала. Ни өченме? Сугыштан соң хәрби разведкада агент булып хезмәт иткән Самраның кушаматы «Красивая» була. Исеме җисеменә туры килеп торгандыр дип уйларга кирәк. Хәтта Президент та котларга килгәч, җиңел гәүдәле, ачык йөзле бу ханымның 100 яшьлек булуына ышанып җитми, күрәсең. Ярдәмчесенең колагына пышылдап: «Ничә яшь дип әйттегез әле?» – дип сорый. Җавапны ишеткәч, Президент үзалдына гына: «Чибә-ә-әр», – дип әйтеп куя.

Самра Бикмеевага исемен күп тапкыр алыштырырга туры килә. Әлбәттә инде, үз ихтыяры белән түгел. Тугач та, әтиәнисе аңа Самира дигән бик матур исем куша. Әмма теркәгән вакытта «и» хәрефен төшереп калдыралар да, ул Самрага әйләнә. Акушерлык мәктәбендә укыганда аны Светлана дип атыйлар. Сугыш кырында кыска гына Соня дип йөртәләр. Сугыштан соң, разведчик буларак, һәр легендага бер исем ябышып кала: Милена, Элишка, Мэри...

«Татар-информ»

Күрсәткән батырлыклары өчен «Кызыл Йолдыз» ордены (1946), «Почет билгесе» (1957), II дәрәҗә Ватан сугышы ордены (1985), шулай ук дистәләгән медаль белән бүләкләнә. Алар арасында «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен», «Сугышчан хезмәтләр өчен» дигәннәре дә бар. Самра Бикмееваның архивында Советлар Союзы маршаллары Иосиф Сталин һәм Георгий Жуков имзасы куелган Рәхмәт хатлары да саклана. Аларның һәрберсе данлы сугыш көннәрен хәтерләтә.

**«Халык дошманы» кызы**

Самраның әтисе Сабир бик белемле мулла була. Властька советлар килгәнче, алар җитешле генә яшиләр. Әмма инкыйлабтан соң, әбисе әйтмешли, ул муллыкны «сыер ялап алган» кебек була. Ул гынамы соң? Әтисен караңгы төндә алып киткәннән соң, 10 яшьлек кызны әнисе, ике абыйсы, бер сеңлесе белән кыш уртасында салкын мунчага куып чыгаралар. Буа районындагы Самра туып-үскән Килдураз авылында укырга китәргә ашкынып торучылар күренми. Ә инде «халык дошманы» баласына бу хакта уйлыйсы да юк. Тик уку теләге шундый көчле. Кыз качып диярлек, бер сүз русча белмәгән килеш Казанга китә, акушерлар мәктәбенә укырга керә. Сеңлесе Наилә дә апасы янына юл тота. Казанга килү беренче чиратта кызга нәрсә бирә? Аның телләргә сәләте ачыла. Ул камил итеп рус телен генә өйрәнеп калмый, чех, немец, инглиз телләрен дә үзләштерә. Сеңлесе Наилә дә шәфкать туташы булып фронтка китә, аннан кайткач, белгечлеге буенча мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында эшли.

**Сугыш**

Сугыш каникулның беренче көнендә башлана. Самра белән Наилә зачетларын тапшыралар да авылга кайтырга җыеналар. Теләкләре дә изге: Казанга рөхсәтсез киткәннәре өчен әтиләреннән гафу үтенергә уйлыйлар. Самра инде акушерлык мәктәбен тәмамлап та килә. Кәефе шәп: берәр туганы чирли калса, шундук ярдәмгә киләчәк. Тик шулвакыт урамнан сабакташы Люсяның тавышы ишетелә:

– Тизрәк мәйданга чыгыгыз. Анда репродуктор аша сугыш башлануын хәбәр иттеләр…

Шулай итеп кызларның планнары чәлпәрәмә килә. Светлананың (аны мәктәптә шулай дип йөртәләр) йөрәге кага башлый. Аннан соң инде ул фронтка, яу кырына элләгүен аңышмыйча да кала. 1941 елның 1 августында хәрби госпитальгә чакырыла. 1942 елда Мәскәүгә медицина хезмәте ротасына күчерелә. 1943 елда аны маршал Жуков командалыгындагы Көнбатыш фронтка җибәрәләр. Кече лейтенант званиесендә операция шәфкать туташы булып хезмәт итә. Бигрәк тә Курск – Орел дугасында хәлләрнең авыр булганлыгын искә ала. Украина, Белоруссия, Латвия, Литва, Польшаны азат итүдә катнаша.

**Василий**

1953 елның февралендә Самра Бикмееваны көтмәгәндә Мәскәүгә, Сталин янына чакыралар. Оекбаш ямап утырган чагы була аның. Куркуыннан хәтта кулындагы энә белән җебе дә идәнгә төшеп китә. «Мине Мәскәүгә, квалификацияне күтәрү курсларына чакыралар. Озакка сузылырга да мөмкин», – дип әйтә ул сеңлесе Наиләгә. Үзе уйлана. Нинди гаебем бар? Василий өченме икәнни? Әмма бу хакта Сталин белмидер, мөгаен.

…1943 елның сентябрендә госпиталь янындагы аэродромга самолет төшеп утыра. Очучы кабинадан сикереп төшә дә канга баткан иптәшен шәфкать туташлары кулына тапшыра. Операция ике сәгать ярым дәвам итә. Яралы егетне коткарып калалар. Самра һава суларга чыга. Василий һаман көтә икән әле. «Сезнең дустыгыз исән калачак. Вакытында китереп җиткергәнсез», – ди аңа кыз. Соңыннан яраланган очучының Мамука Габелия булуы да, Василийның кем икәнлеге дә ачыклана. Василий бер атнадан иптәшенең хәлен белергә кабат килә. Янып торган өрәңге яфракларыннан кызга гөлләмә бүләк итә. Мамуканы килеп алырга вәгъдә бирә. Әмма килми. Самра моның сәбәбен сугыштан соң гына белә.

Казанда алар кабат очрашалар. Госпитальгә Василийны бик авыр хәлдә китерәләр. Кыз аны башта танымый да. Соңрак исә барысын да искә алып, озак кына сөйләшәләр. Казанга сөрелгән бу кешенең язмышы Самраны бик дулкынландыра. Ә теге вакытта, Мәскәүгә баргач, ул Сталин янына керә алмый. Юлбашчының үлеме турындагы хәбәрне ишетеп, кире кайтып китә.

**Берлин**

1945 елның маен Самра Берлинда каршылый. Рейхстагның яулап алынуын күрә.

– Без ул чакта аның әһәмиятен әллә ни аңлап та бетермәгәнбез инде, уйламадык та, – ди ул, Рейхстагта автограф калдыра алдыгызмы, дигән сорауга җавап итеп.

Бервакыт шулай кызлар белән урамнан әйләнеп керергә булалар. Бөтен җирдә – җимереклек. Сугыш беткәнгә, җиңү килгәненә ышанасылары да килми. Койма янындагы бер зур ташка ял итәргә утырулары була, бер баланы якасыннан тоткан фриц килеп чыга. Сабый җансыз курчак шикелле аның кулында чайкала, үзе ачыргаланып елый. Кызлар аны коткарырга ашыгалар. Самра (ул сугыш кырында Соня була) фрицка ябыша. Тегесе көтелмәгән бу хәлдән егылып китә, кызга ташланып, өстенә килеп төшә. Шулвакыт ату тавышы ишетелә. Канау артыннан совет солдаты күтәрелә.

– Мин Гази исемле. Иптәшләрем Гена дип йөртәләр, – дип таныша ул кызлар белән.

Соня канатланып китә:

– Бу – безнең татар исеме бит!

– Әйе, мин – башкорт татары, Башкортстаннан.

– Ә мин – татар татары.

– Кызлар, госпитальнең кайдалыгын белмисезме? Рейхстагка байрак элгәндә азрак эләгеп китте минә.

– Байракны элдегезме соң?

Соня аның канга баткан колагын, кулын шунда гына искәреп ала. Колагы инде шактый гына шешеп тә киткән. Госпитальдә Самрага операция ясарга кушалар. Кыз егетне кыйпылчыклардан чистарта.

…Тирә-якта шау-шу, барысы да җиңү килгәнгә шатлана. Өйләренә кайту турында хыялланалар. Соняның да шатлыгы эченә сыймый. Тиздән туган авылы Килдуразны, Казанны, әтисен күрәчәк бит. Иптәш кызларына китәргә рөхсәт бирделәр инде. Аңа гына һаман хәбәр юк.

Көн артыннан көн үтә, хисләргә бирелгән шаукым бетә, Самраның кинәт кенә кәефе төшә башлый. Иң кадерле кешеләрен – ире Михаил белән улын югалту кайгысы аңа төшенкелек китерә. Аларның никахларын госпиталь хирургы теркәгән була. Миша минада шартлап һәлак булганның икенче көнендә Самра үле бала таба. Куркыныч мизгелләр искә төшеп, кинәт кенә тормышының мәгънәсе югалган кебек була. Менә шул вакытларда НКВДдан Анисимов атлы кеше килеп, хезмәттәшлек итәргә тәкъдим ясый да инде. Башта ул аңа «җиңел» задание бирә: һәлак булган полковник Зверев урынына куелган яңа баш табиб артыннан күзәтергә куша. «Берәр шикле әйбер булса, син миңа хәбәр генә итәрсең, мин гел күрше вагонда булам», – ди. Шулай итеп, Самра Бикмеева агент булуын сизми дә кала.

**Разведка**

1943 елда дуслык, үзара ярдәм, хезмәттәшлек турында СССР белән Чехословакия арасында килешү төзелсә дә, совет хәрби разведкасы сугыштан соң бу илгә агент җибәрергә карар кыла. «Халык дошманы» кызы булудан, ачлык, хәерчелектән интегеп яшәгән, сугышта ирен, баласын югалткан Самра өчен бу тәкъдим буламы, әллә инде боерыкмы – боларның берсе дә роль уйнамый. Эш аны үзе сайлап ала. Әмма шымчылык итү генә күңеленә ятып бетми. Әле ярый аның беренче чираттагы максаты билгеле бер кешеләрнең эшчәнлеген дөрес юнәлешкә кертеп җибәрү була.

1948 елда ул Румыния башлыгы Константин Йон Пархон белән таныша. Аның бурычы – Үзәктән килгән заданиеләрнең үтәлешен тикшерү һәм бу хакта тиешле җиргә хәбәр итү. Агент белән Президент арасында хәтта «мәхәббәт» тә кабына. Милена-Самра ул рольне дә уйнарга тиеш була. Әмма сипкелле, шаян Мишасы яулап алган йөрәген ул беркемгә дә ачарга җыенмый. Соңрак, вазгыять катлауланып китеп, кызның агент икәнлегенә төшенгән, бик хәтере калган Президентны разведчик әллә ни кызганмый да кебек. Шулай тиеш дип таба. Әмма Константинның фотосын әлегә кадәр саклый ул.

1950 елда Самра Бикмеева Казанга кайта. 3 нче номерлы бала табу йортына акушерка булып урнаша. Аннан хәрби госпитальдә, хәрби частьларда эшли. 1985 елда лаеклы ялга чыга.

Самра апа бүген сеңлесе Наиләнең кызы Гөлсинә Галләмова белән яши.

«Сугыш мәхшәре әле дә булса төшегезгә керәме?» дигән сорауга ул болай җавап бирә:

– Гомер үткән саен андагы вакыйгалар ешрак искә төшә, төшкә дә керә. Мин баштарак сугыш турында кино да карый алмый идем. Чөнки чынбарлык бик күпкә куркынычрак. Шуңа күз алдына китерәсем дә килми. Әтием дүрт ел буена Беренче Бөтендөнья сугышында булган, ярты ел җәяүләп өйгә кайткан. Ул да андагы кичерешләре турында искә алырга яратмады. Бөек Ватан сугышы да безнең гаиләне аямады: ике абыемны алып китте. Олысы Таһир 1942 елда Донбасс өчен сугышканда, икенчесе Наҗи 21 яшендә Сталинградта һәлак булды.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

# ТАМЧЫДАН КҮЛ ҖЫЕЛА

Питрәч

**Халык Ватанны сакларга китәргә әзерләнгән улларына кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Тамчыдан күл җыела шул. Әнә Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авылы халкы да мобилизацияләнгән солдатларына йон оекбашлар бәйли башлаган. Күпләп сарык асраучы Ольга Семенова, гаиләсе, авылдашлары белән киңәшләшеп, әлеге эшкә 20 килограмм сарык йоны биргән. Халыкның бер өлеше, авыл мәдәният йортына җыелышып, шул йонны эшкәртә, эрләп, катып тора, икенче берәүләр әзер җептән оекбашларны өлгертеп бара.**

– Илдәге вакыйгаларга битараф кала алмадык. Безнең мәдәният йортында «Йомгагым» дигән клуб эшләп килә, алдагы елларда да төрле кирәк-яраклар бәйли идек инде. Быел солдатларыбызга ярдәм итәсебез килде. Тиздән кыш җитә, аяклары өшемәсен. Туган йортларыннан аерылсалар да, шушы оекбашлар «безне онытмаганнар икән әле» дип, күңелләрен җылытып торсын, – ди Ольга Семенова.

Оекбашларны хатын-кызлар гына түгел, ирләр дә бәйли. Керәшен Сәрдәсе авылы музееның фәнни хезмәткәре Олег Волков өеннән йон эрли торган машина да алып килгән. Бәйләү эшенең нечкәлекләрен ул кечкенәдән күрше апасыннан отып алган икән.

– Үземне белгәннән бирле бәйлим, ә менә эрләргә 25 яшемдә генә өйрәндем әле. Хатын-кыз эше дип тормыйм, миңа ошый. Кышкы кичләрдә ике кулга бер эш ул. Менә бүген дә солдатларыбызга җылы оекбашларны вакытында өлгертергә дип бирегә килдем, – ди Олег Волков.

Мария Кузнецова өмәгә күптән түгел генә кушылган, шифаханәдә саулыгын ныгытып кайткан.

– Авылга кайтуга, монда килдем. Бераз булса да файдасы тисен дип, өйдә бәйләгән йон оекбашларымны да алып килдем. Араларында хатын-кызларга ярый торганнары да бар, табибларга, шәфкать туташларына булса да ярап куяр. Без солдатларыбызга һәрвакыт ярдәм итәргә әзер, шалтыратуга килеп җитәбез, атыбыз җигелгән, – дип елмая Мария Кузнецова.

Оекбаш бәйләү белән генә чикләнмәгән авыл халкы. Узган атнада авылның үзешчән артистлары хәйрия концерты да оештырган. Һәркем, мобилизацияләнгән якташларына дип, булдыра алган кадәр акча тапшырган.

– Безнең өчен мобилизация хәбәре көтелмәгән булды. Шуңа да чакыру килгән барлык биш солдатыбызның гаиләсенә матди ярдәм күрсәтергә булдык. Аларга солдат капчыклары, беренчел кирәк-ярак сатып алдык. Битараф булмаган авыл халкы ярдәме белән барлыгы 116850 сум акча җыелды. Акчалар әле дә килеп тора. Барысын да солдатларның якыннары аша тапшырып барабыз. Авыл советы рәисе буларак, егетләргә хәбәр тарату миңа йөкләнгән. Аларның барысы да миңа якын, авылыбыз зур түгел бит, йортларының ишеген шакып кергән вакытта йөрәк кысылып куя. Ярый әле егетләр хәбәрне аңлап кабул итте. Исән-сау әйләнеп кайтсыннар гына инде, – ди Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Николай Морозов.

Без дә авылдашлары, якыннарының хәер-фатихасы белән киткән егетләрнең барысы да исән-имин туган якларына әйләнеп кайтсын, дигән теләктә калабыз.

Алисә ШӘРӘФИЕВА

Үрнәк

### КАРИНА ШИҺАПОВА:

## *«Волонтерга салада да эш җитәрлек»*

Мамадыш

**Ярдәмнәрен кемгә тәкъдим итәргә белми утыручылар да юк түгел. Мамадыш районының ирекледәр хәрәкәте үзәген җитәкләүче, «3D – Дорога добрых дел» һәм башка проектлар авторы Карина Шиһапова әнә шулай ди. Кечкенә шәһәрләрдә һәм авылларда волонтер булуның нинди аермасы бар?**

**«Баштарак волонтерларга сәерсенеп карадылар…»**

Каринаны туган районына кайтып, волонтерлык үзәге ачарга менә нәрсә этәргән:

– Мин кечкенә авылда туып-үстем. Зур шәһәрләрдә волонтерлар турында күп сөйләсәләр, без бу турыда ишетеп тә белми идек. Ә бит волонтерлар һәр җирлектә бар. Аларга авылда да эш җитәрлек. Ләкин башка берәүләргә ярдәм итәргә ашкынып торучылар үзләренең волонтер булуын да, ярдәмнәрен тәкъдим итәр өчен кая мөрәҗәгать итәсен дә белми. Волонтерлар өчен уздырыла торган форумнар, төрле грант программалары турында әйтеп тә тормыйм инде. Мамадышка кайтып, бу мәсьәләне хәл итәсем килде. Бу игелекле җаннарга волонтерлык турында сөйләргә, ярдәм итә алу өчен мөмкинлек тудырырга теләдем. Һәм әкренләп бу теләгемне чынга ашырам кебек. Безнең үзәк турында белүчеләр, ярдәм тәкъдим итеп яки ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр көннән-көн арта.

Моның өчен Карина һәм аның командасы, шәһәр һәм авыл мәктәпләренә барып, «Тормыш дәресләре» уздыра, шунда ук актив балалар белән танышып, бераздан бергә эшли башлый.

– Волонтер булырга теләк белдерүчеләргә «Добро.ру» сайты турында сөйлибез. Алар анда теркәлеп, махсус курслар узарга тиеш була. Бу – төп таләпләребезнең берсе. Ярдәм итүнең дә үз җае, тәртибе бар бит. Ул ярдәмең зыян түгел, файда китерсен, дисәң, әлбәттә, – ди әңгәмәдәшебез.

Карина Шиһапова сүзләренчә, баштарак җирле халык волонтерларга сәерсенеп, шикләнеп караган. Аеруча, өлкән яшьтәгеләр. Хәзер инде ярдәмчеләрен әллә кайдан танып алып, ачык йөз белән каршы алалар икән.

– Кечкенәрәк шәһәрдә эшләүнең тагын бер уңай ягы – мәгълүматның тиз таралуы. Безнең хакта да бик тиз белеп алдылар. Хәзер инде һәрберебезне диярлек беләләр, ярдәмнән баш тартмыйлар, – ди ул.

**Яше дә, карты да**

Волонтерлык үзәге шәһәрнең Яшьләр үзәге базасында эшли. Хәзерге вакытта үзәктә даими рәвештә эшләүче 30лап волонтер исәпләнә икән. Шул ук вакытта «3D – Дорога добрых дел» үз канаты астына район мәктәпләренә карый торган 10 отрядны алган. Барысын бергә санасаң, район волонтерларының саны 100дән арта, ди Карина.

– Аларның күпчелеге – мәктәп укучылары, аларның әтиәниләре һәм укытучылар. Өлкән сыйныф укучылары белән аерым, кечкенәләр белән аерым эшлибез. Шәһәрнең Политехник көллиятендә дә волонтерлык отряды бар. Эшли торган яшьләр, урта яшьтәгеләр дә безнең хәрәкәткә битараф түгел. Безнең сафта «көмеш», ягъни өлкән яшьтәге волонтерлар булу белән дә горурланабыз. Ярдәм итәргә ашкынып торучыларның күп булуы төрле юнәлешләрдә эшләргә мөмкинлек бирә.

Өлкән яшьтәге, ялгыз кешеләргә булышу таләп ителсә дә, төрле чаралар уздырасы булса да ярдәмгә килә алар. Моннан тыш, күпбалалы яки, киресенчә, тормышлары бик үк барып чыкмаган гаиләләрдә, приютларда тәрбияләнгән балалар өчен төрле мастер-класслар оештыралар, йортсыз калган эт-мәчеләргә ярдәм итәләр, чисталык өмәләре уздыралар.

– Мобилизациягә эләккән ир-атларның гаиләләрен дә ялгыз калдырмыйбыз, кулдан килгәнчә ярдәм итәбез. Гуманитар ярдәм җыюда да актив катнаштык. Безнең волонтерларның 70 проценты диярлек – авылда яшәүчеләр. Алар да үз җирлекләрендә бик актив эшлиләр. Авылда яшәүче волонтерларның күзләре яна, алар белән эшләү тагын да рәхәтрәк. Үз җирлекләрендә генә яткырмыйбыз, төрле форумнарга, конкурсларга җибәрергә тырышабыз, грант программаларында катнашабыз. Алар үзләренең кирәк булуын, нинди зур эш башкаруларын аңларга тиеш, – ди Карина.

**«Үсмерләр башкаларга ярдәм итәргә ояла…»**

Әңгәмәдәшебездән үсмерләр белән эшләүнең үзенчәлекләрен дә сораштык. Яшь буын игелеклелек, мәрхәмәтлелек кебек төшенчәләр белән таныш түгел, диючеләр дә бар бит.

– Безнең күпчелек волонтерларыбыз – 15–18 яшьлекләр. Аларның эчке дөньясы, теләк-максатлары белән бераз булса да танышырга өлгергән кеше буларак, шуны әйтәсем килә: хәзерге яшьләр бу төшенчәләр белән бик яхшы таныш. Ләкин алар үзләрендәге шушы күркәм сыйфатларны каядыр тирәнгә күмеп куйган да күрсәтергә оялалар. Аеруча егетләр. Күп кенә үсмерләр, башка берәүгә ярдәм итүләрен яшьтәшләре дөрес аңламас, көләрләр, дип борчыла. Бу курку волонтер булып йөрүче яшьтәшләре, аларның эшчәнлеге белән якыннан танышкач юкка чыга. Шуңа да аларның башкаларга ярдәм итү теләген күреп алып, вакытында дөрес юнәлеш бирергә кирәк, – ди Карина. – Үсмерлек яшенә җиткән егет-кызлар үзләрен табарга, башкалардан аерылып торырга тырыша, дөньяны үзгәртергә тели. Волонтерлык хәрәкәтенә кушылганнары бу теләкләрен кешеләргә ярдәм итеп, чынга ашыра. Алай гына да түгел, алар үзләрен төрле юнәлешләрдә сынап карый. Иң кызыклы идеяләрне дә нәкъ менә яшьләребез тәкъдим итә. Алар белән эшләү рәхәт.

Каринаның хыялы – яшьләргә башкаларга ярдәм итүнең ояла торган гамәл булмавын аңлату, аларга һәм башка буын вәкилләренә волонтерлыкның кызыклы булуын исбатлау.

– Татарстанда волонтерлык хәрәкәтенә бик зур игътибар бирелә. Бу – үзеңне күрсәтү өчен дә файдалы өлкә. Республикада төрледән-төрле грант программалары, форумнар уздырыла, киләсе җәйдә волонтерлар өчен лагерь да оештырылачак. Кыскасы, бөтен мөмкинлек тә бар, теләк кенә кирәк! – ди Карина.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Спорт

«Татар-информ»

# *Казанның Камиләле кичләре*

Казанда Камилә Вәлиева көннәре узды. 16 яшьлек якташыбыз спортта тәүге адымнарын ясаган бозда илдә иң шәп фигуралы шуучы булуын раслады. Россия Гран-при ярышларының өченче этабында ул көндәшләрен 30 баллга артта калдырды. Егылса да, еламады.

Шимбә һәм якшәмбе көннәрендә Боз сараеның тамашачы белән тулуы, әлбәттә, Камилә Вәлиеваның Казанга кайтуына бәйле булды. Ике як та бер-берберенә булган мәхәббәтен яшермәде. «Бозга чыккач, тамашачының миңа җылы мөнәсәбәтен сиздем», – диде Камилә, чыгышы тәмамлангач. Үзенә аерым мөнәсәбәт булудан файдаланып, чыгышы тәмамлангач та боздан кереп китмәде, килеп чыкмаган дүртле сикерүне кабат эшләп карады. Бу юлы да булдыра алмады. Әмма андамыни хикмәт?! Тамашачы Камиләне озаграк күрә алуына сөенде. «Бераз вакыт узсын әле, мин аны барыбер сикерәчәкмен», – диде спортчы. Бу инде февральдә бөтен дөньяның игътибарын үзенә җыйган кечкенә кызчык түгел. Пекин Олимпиадасы 16 яшьлек кызны, үзе теләмәсә дә, тизрәк үсәргә мәҗбүр итте. Зурлар бирмәгәнне ул үзе хәзер каерып алырга тырышачак. Чыгышы тәмамлануга ук боздан кереп китмәве – әнә шуның нәтиҗәсе.

Тамашачы, әлбәттә, Олимпиадада булган вакыйгаларны искә алды. Камиләнең чыгышында да сизелде ул хатирәләр. Трибунада утыручылар арасында күз яшьләрен яшерә алмаучылар да булды. Спортчының үзен исә уенчыкка күмделәр. Камилә – иң танылган татар хатын-кызларының берсе. Тамашачылары арасында да бар иде андый кеше. Гран-при ярышын карарга Россия Үзәк банкы рәисе Эльвира Нәбиуллина да килгән иде.

Боз сараенда Казан кызларының чыгышы моның белән генә бетмәде. Парлар ярышында тагын бер якташыбыз Евгения Тарасова Владимир Морозов белән җиңүче исемен яулады. Ясминә Кадыйрова исә Валерий Колесов белән икенче урынны алдылар. Ясминә дә Казанда туып-үскән, аңа – 17 яшь. Хәзер ул Санкт-Петербург командасы өчен чыгыш ясый. Заманында Этери Тутберидзеда шөгыльләнгән иде. Узган ел исә парлы ярышларда чыгыш ясый башлады.

# Суккан саен керми

Казан хоккейчылары рәттән ике уенда җиңү яулады. Мондый хәлнең инде сентябрь ахырыннан бирле булганы юк иде. Дөрес, Олег Знарок командасы көндәшләрнең берсен дә төп вакытта җиңә алмады. «Салават Юлаев»ны буллитлар ярдәмендә ота алсалар, Череповецта «Северсталь»гә каршы узган матчта өстәмә вакытта гына уңышка ирештеләр. Бүген «Ак барс» Түбән Камада «Нефтехимик» белән очраша.

Уфа командасына каршы узган матчта «Ак барс» оттырып барган уенны үз файдасына төгәлләде. Череповецта исә, киресенчә, 2 алкалык өстенлекне кулдан ычкындырды. Җиңелүдән бары капкачы Тимур Билалов кына саклап кала алды. Хәлиткеч алканы Илья Сафонов кертте. Бу – 21 яшьлек һөҗүмченең яңа сезондагы 9 нчы уңышы. Ул «Ак барс»тагы иң нәтиҗәле ике һөҗүмченең берсе санала. Икенчесе – Александр Радулов. НХЛдан кайтып, Казан командасының иң еш телгә алынган уенчысына әверелгән хоккейчының да 9 алкасы бар.

Соңгы ике очрашуда бозга «Ак барс»ның капитаны Данис Зарипов та чыкты. Үзе әйтүенчә, әллә ни файдасы булмаган. Әмма Данисның тагын да зуррак вазыйфасы бар: команданы берләштерү. Алка кертә белүчеләр җитәрлек. Әмма бердәмлек җитми. Шуңа булдыра да алмыйлар. «Командага ышанабыз. Уңышлы уеннардан соң ышаныч барлыкка килә. Һәрвакыт без теләгәнчә килеп тә чыкмый», – ди ул. Соңгы вакытта кәефләр шәптән түгел. Бүгенге шартларда тамашачының күңелен күрер өчен, алка сугучы егетләргә икеләтә тырышырга кирәк түгелме? «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе Гагарин Кубогын биш мәртәбә откан хоккейчыга әнә шундый сорау бирде. «Әлбәттә, мобилизация һәм башка вакыйгалар турында сөйләшми тормыйбыз. Егетләр җаваплылыкны аңлый. Тамашачыга күбрәк шатлык бүләк итәсе килә. Әмма беркем дә җиңел буласын әйтмәде. Алда уеннар күп әле. Кулга-кул тотынып, бергәләп тырышырга кирәк», – ди Данис Зарипов.

**КӨНЧЫГЫШ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ**

| | команда | уен | очко |
|---|---|---|---|
| 1 | Металлург | 27 | 37 |
| 2 | С. Юлаев | 26 | 37 |
| 3 | Автомобилист | 26 | 34 |
| 4 | Сибирь | 28 | 33 |
| 5 | Адмирал | 27 | 32 |
| 6 | Авангард | 27 | 29 |
| 7 | Ак Барс | 26 | 28 |
| 8 | Барыс | 27 | 25 |
| 9 | Трактор | 27 | 25 |
| 10 | Нефтехимик | 26 | 21 |
| 11 | Амур | 25 | 20 |

ak-bars.ru

# ҺӘР ЗАМАННЫҢ – ҮЗ МӨҺАҖИРЛЕГЕ?

**Премьерадан соң уйлану**

**Татар дөньясында Мәхмүт Галәү исеме бик тансыкка гына яңгырый. «Мөһаҗирләр», «Болганчык еллар» дилогиясе авторы үзе дә фаҗигале язмышка дучар булган, әсәрләре дә безнең көннәргә русча тәрҗемәдә генә барып ирешкән. Ниһаять, «Мөһаҗирләр» фаҗигасе Камал сәхнәсенә күтәрелде. Аңа нинди мәгънә салынган? Без әнә шул хакта уйландык.**

Быелның маенда Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектакленең бер өлешен «Ирдәүкә» исеме белән халыкка тәкъдим иткән иде. Ул чакта ук режиссер Мәхмүт Галәү әсәрен татарның энциклопедиясе дип атады. Чыннан да, спектакльдә гаилә традицияләренә, гореф-гадәт, йолаларга урын мулдан бирелгән. Күп күренешләр, әйтик, урак уру, җыен, яшьләрнең беренче күрешүе пластика ярдәмендә күрсәтелә. Халыкның байлар кулында марионетка, курчак булулары да хореография аша бик калку бирелгән. Димәк, бу – хореограф Нурбәк Батулла спектакле дә.

Әсәрнең төп герое – ирдәүкә Сәҗидә (Ләйсән Гатауллина) үскән Йосыф (Татарстанның атказанган артисты Илтөзәр Мөхәммәтгалиев) белән Сылу (Татарстанның атказанган артисты Ләйсән Рәхимова) гаиләсе – спектакльдә үрнәк мисалларның берсе. Гәрчә китаптан Йосыф картның кул уйнатырга яратуы аңлашылса да, спектакльдә бу тема «йомылган». Йомылган, төшеп калган темаларның булуы, бер караганда, табигый. Спектакльнең мөмкинлекләре, ничек кенә карасак та, чикле. Шуңа күрә, мөгаен, үзәккә Сафа (Татарстанның халык артисты Илдус Габдрахманов, Фәннур Мөхәммәтҗанов) белән Сәҗидә язмышы алынгандыр да.

Әсәр ни хакында соң? Бу сорауга җавап биргәнче, спектакльнең янә бер табышын искәртеп үтик: спектакль кызу бер темпта барганда, хатын-кыз актерлар кинәт образдан чыгып, Мәхмүт Галәүнең фаҗигале язмышы турында сөйли башлый. Тамашачыга «Канлы тамгалар» эпопеясының 4 китаптан торганлыгы турында җиткерелә. Эпопеяның беренче ике кисәге – «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары гына безнең көннәргә рус телендә килеп ирешә. «Болганчык еллар»да иске татар авылының көнкүреше, гореф-гадәтләре, ачлык ел вакыйгалары, ә «Мөһаҗирләр»дә 1897 елгы халык санын алу вакыйгасына бәйле рәвештә кузгалган чуалышлар, бөлгенлеккә төшкән татарларның, бәхет эзләп, Төркиягә күчеп китүләре һәм андагы язмышлары сурәтләнгән. Романнарның татарча кульязмалары Казанның «Татиздат» нәшриятында бастырылмыйча ятып, ахырда юкка чыккан. Шуңа күрә соңрак алар 1931 һәм 1934 елгы русча басмалары нигезендә яңадан татарчага тәрҗемә ителгән. Сәхнәдә актерлар Мәхмүт Галәүнең бу хактагы хатларыннан өзекләрне дә укыйлар.

Сүз уңаеннан, спектакльне авторның оныгы Анастасия Галәү дә карады. Аның әйтүенчә, Фәрит Бикчәнтәев автор текстыннан ераклашмаган, киресенчә, мөмкин булганча якын торган:

– Спектакльдә Мәхмүт Галәү авазы ишетелә. Бу – бик гаҗәеп нәрсә. Иң гаҗәпләндергәне – ул автор фикерен заманча итеп сурәтли белә. Бернәрсә дә үзгәрмәгән. Шул ук проблемалар, шулай ук безне бүлгәләргә тырышулар, каршылыклар…

Язучы Ләбиб Лерон да премьераны тәэсирле дип атады:

– Спектакльне ирексездән бүгенге вазгыять белән чагыштырып карыйсың. Миңа калса, төп фикерне әйтә алганнар. Дөрес, Мәхмүт Галәү дилогиясе бик катлаулы һәм аның эчтәлеген сәхнә әсәренә тулаем сыйдырып булмый торгандыр да. Ничек булса да, уйландырды. Хәтта авторның язмышы хакында да моңсу уйларга салды.

Галим Зөфәр Рәмиевкә спектакль үз гаиләсенең үткәннәрен искә төшергән:

– Спектакльдә тарихи дөреслек төрле алымнар белән чагылдырылган. Дөрес, артык натурализмга бирелгән күренешләр дә бар. Әйтик, ялгыз хатынны туку станогында көчләү күренеше. Әйе, әсәрдә бу хакта язылган, әмма андый күренешне сәхнәләштергәндә, халыкка тәэсир итәм дип, чама хисен югалтырга ярамый. Ә Сәҗидә язмышы ул – күп гаиләләр тарихында кабатланган язмыш. Мәсәлән, минем үземнең дә әни ягыннан дәү әниләрем икәү иде. Бабай 1927 елда вафат булды, ике дәү әни бергә 18 ел тату яшәделәр. Берсе мине уллыкка алырга да йөргән иде әле. Әле дә Федосеевская урамындагы 13 нче йорт күренеше күз алдында. Аннан кулаклаштыру башлана, әни сөргеннән көч-хәл белән котылып кала. Кыскасы, спектакль үз гаиләм фаҗигаләрен дә янә искә төшерде. Спектакль кыю куелган. Үз җиреңдә дә, чит илдә дә син – күзәтү астында. «Фәлән баш сарык җибәрдек, каршы алыгыз», – дигән сүзләрдә генә дә халыкның ачы язмышы чагыла бит.

Сафа бәхет эзләп чыгып киткәндә, илдә кемнәр кала? Әсәрдә бу җәһәттән Фәхри образы бар. Ул ярлыларны яклый, татар баеның үз кесәсен кайгырту җәһәтеннән никадәр сатлык булуын күрә. Революционер. Бу образ спектакльдә төшеп калган. Аның урынына патшага динебезне тыйма дип язылган прошениене ым-ишарәләр (чукраклар теле) белән бирү күренеше кертелгән. Ул чактагы самимилек һәм телсезлекнең нәтиҗәләре күз алдында, хәтта Галәү нәселе язмышында да күренә инде.

«Татар-информ»

Һәр заманда бәхетсезлектән качу, мөһаҗирлек бар. Тик ул чактагы мөһаҗирлек белән хәзергене чагыштырырга һич кенә дә ярамый. Әдәбият белгече Миләүшә Хәбетдинова әнә шул фикердә:

– Әлеге куелыш режиссер эчендә ике шәхес көрәшкәнен күрсәтте. Бер яктан ул символик мәгънәдә татар авылының тормышы, милли үзенчәлеген тасвирларга омтыла, ләкин форма белән мавыгып, зур темага чыга алмыйча газаплана. Без татар халкы язмышын, аның фаҗигасенең төп сәбәпләрен Галәү дәрәҗәсендә сәхнәдә ачылганын күрмибез. Хикмәт шунда: Фәрит Бикчәнтәев – дөнья әдәбияты тәэсирендә формалашкан кеше. Һәм бу спектакльдә Көнбатыш Европа әдәбияты йогынтысы бигрәк тә чагыла. Әйтик, мәзәкче (тиле) образы. Аны тыңлаганда, кайчак Хуҗа Насретдин күләгәсе күз алдына килә. Ул Сафага бәхет турында сорау бирә. «Нәрсә ул бәхет?» дигән сорауга спектакльнең төп герое, үз тәҗрибәсеннән чыгып: «Бәхет ул – кеше үзе икән», – дип җавап бирә. Ләкин без бит тарихи романны сәхнәгә чыгардык! Гасыр башында татарлар бәхет эзләр өчен түгел, ә үз телен, динен саклап калу өчен авылы белән күтәрелгән. Шушы фаҗиганең төп сәбәпләре сәхнәдән читтә калган. Аларны бүгенге качаклар белән чагыштыру да урынсыз. Режиссер бәхетсезлек гаебен хатын-кыздан күрә. Бу фикерне ачуга бик күп вакыт бирә, кызык алымнар файдалана. Әйдәгез, татар мәкальләрен искә төшерик: «Бәхетең ирдән булмаса, илдән булсын», «Кызны бәхетле иткән кеше – ир». Кайда спектакльдә Сафаның антиподы – Фәхри? Аны режиссер юк иткән. Спектакльдә ирдәүкә барысын да хәл итә, ул бәхетсезлеккә китерә булып чыга түгелме? Режиссер кемне тәнкыйтьли? Хатын-кызны… Шулай итеп, язучының дилогиясендәге төп фикер юкка чыга.

> Спектакльдә иң истә калган фикерне Зөһрә карчык – Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Алсу Гайнуллина әйтә. «Фанилыкта патшаларның гөнаһын күтәрергә ярый әле халык бар, бакыйлыкта нишләрләр икән, мин бик җәллим аларны», – ди ул. Һәртөрле кысаларга һәм вакыт чикләүләренә сыеша алмаган фикер бу.

Хәер, актерларның киемнәре дә бернинди кысага сыешмый. Үзләре элекке, шул ук вакытта хәзерге заманча, ярым хәрби киемнән алар. «Ә халыкны бәхетле итәрлек ил кайда?» дигән сорауга җавапны Мәхмүт Галәү дә белмәгәндер. Юкса, шул илдә гомерен саклап кала алган булыр иде.

Сүз уңаеннан, спектакльдән соң тамашачыга туфрак салынган савытлар бүләк итәләр. Бер уч туфракны гадәттә туган илдән китүчеләр истәлеккә үзләре белән алалар. Яисә бер уч туфрак үлгән кеше кабереннән алып кайтыла. Бусын гади бер уенчык итеп кабул итәргәме? Әллә анда югарыда телгә алынган фикерләрнең берсе ятамы? Һәркем үзенчә хәл итә. Ничек булса да, ямансу әле.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

# «ДӘҮ ӘТИ ДӘ, ДӘҮ ӘНИ ДӘ – ТЕЛЕФОН»

## БӘХЕТЛЕ ТАТАР ГАИЛӘСЕ НИНДИ БУЛА?

**Дин, тел, хөрмәт, мәхәббәт. Татар гаиләсенә нигезне шушы сыйфатлар сала. Шулар ук саклап калырга да ярдәм итә. Казан кооперация институтының татар мәдәнияте үзәгендә «Татар гаиләсенең үткәне һәм киләчәге» дигән темага фикер алыштылар. Чакырылган кунаклар арасында дин әһелләре дә, җәмәгать эшлеклеләре дә, сәнгать, мәдәният вәкилләре дә бар иде.**

### Өмет бармы?

«Бетәбез!» – дип түгел, татар гаиләсе бар, булган һәм булачак дип эшләргә кирәк. Бөтенроссия «Татар гаиләсе» фонды башкарма директоры Миләүшә Гайфуллина фикере бу. Күп еллар дәвамында алып барган эшчәнлеге тәҗрибәсеннән чыгып, үрнәкләрнең күп булуын әйтә ул. Татарстанда гына түгел, республикадан читтә дә гореф-гадәт, милләт сагында торган гаиләләр шактый. Күптән түгел Чиләбе өлкәсендә булып, шуңа инанып кайтканнар.

Күп вакытта эшләр сөйләшүдән һәм кәгазьдән ары узмый. Озак еллар дәвамында татар яшьләрен таныштыру-кавыштыру эшләрен алып баручы Мөселман хатын-кызлары берлеге рәисе Наилә Җиһаншина, гаилә корганчы, булачак ир белән хатынны дөрес итеп тәрбияләргә кирәк дигән фикердә.

– Бик күп кешеләр белән эшлибез. Карыйм: күпләр ялгыз. Йә кияүгә чыга алмаган, йә аерылган, йә башка сәбәпләре бар. Бер караганда, ничек инде шулай, дип тә куясың. Кеше бит гаилә корырга омтыла, ул моны тели. «Нишләп башлы-күзле түгелсең?» – дип сорау бирсәм, җаваплары: «Яхшы кеше юк бит». Шунысы да бар: танышырга дип мөрәҗәгать итүчеләр үз анкеталарында «урыс булса да ярый» дип яза. Без исә аңлату эшләрен башлыйбыз. Үз кавемеңнән булган кеше белән бәхетле гаилә корырга кирәклеген аңлатабыз. Безнең үзәк ачылган көненнән башлап 3 меңләп кешене парлы итте, шөкер, – ди ул. – Күпләр төптән уйламый. Яхшы кеше булсын да, бетте. Әмма бит киләчәктә кыенлыклар туарга мөмкин. Берсе намазын укыр, берсе чукыныр. Олыгайгач, якын мөнәсәбәтләр булмас. Шунысын да уйларга кирәк бит әле аның. Җәннәткә омтылуыбызның асылы – яраткан кешеләребез белән бергә булу теләге. Менә шуларын аңлата торгач, «миңа урыс та ярый» дигәннәрнең карашларын үзгәртәбез.

Наилә Җиһаншина әйтүенчә, татар гаиләсен саклап калу өчен, татар гаиләсе мәктәбен дә булдыру кирәк.

– Әниләр кызларын: «Кызым, син бик әйбәт, сиңа ирең тиеш», – дип тәрбияли. Улларын да: «Улым, син әйбәт, хатын алырсың да, ул сиңа тиеш булыр», – дип үстерә. Ике тиешне берничек тә кавыштырып булмый ул. Мөнәсәбәтләре нык булмый, һәркайсы үз ягына тарта. Әле икесе дә холык ягыннан көчле зат булса!.. Әзерлисе иде яшьләрне. Кайчакта кызыбыз уңган-тырыш, матур да була, юньле егет эләкми. Йә киресенчә. Яшьләрне дөрес итеп сайларга өйрәтәсе иде. Безнең проблемалар күп түгел, бармак белән генә санарлык алар. Әмма алар килеп чыкканчы хәл итү юлларын белү зыян итмәс, – дип саный Наилә Җиһаншина.

### Урысча уйлап, татарча дәшмәү

Телне буыннан-буынга тапшыру, дини тәрбиянең әһәмиятенә Тәтеш районының «Ак калфак» һәм «Татар гаиләсе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмалары җитәкчесе Рима Сафиуллова игътибар итте.

– Кайчагында балаларны үзебез үк бозабыз. Татарча дәшәр урынга, үз балалары белән күпләр вата-җимерә рус телендә сөйләшә. Телебезнең бетә баруына без үзебездән кала башка берәүне дә гаепли алмыйбыз, – ди ул. – Балага телне дә, милләткә мәхәббәтне дә яшьтән үк салырга кирәк. Алайса хәзер кайсылары, телне институтта да өйрәнә ул, дип кенә җибәрә. Өйрәнми ул аны. Бишек җырлары, мөнәҗәтләр аша телебезне балаларыбызга сеңдереп була. Мин Тәтештә һәрбер авылда «гаилә җитәкчесе» дигән кешеләр куя башладым. Бездә тәрбия эшләре буенча күп эш башкарыла.

Рима ханым, эшчәнлегенә бәйле рәвештә, төрле төбәкләрдә дә, күрше республикаларда да еш кунак була.


Ольга Орехова

Татар гаиләсендәге тәрбия мәсьәләсе турында сүз чыккач, Чувашия тәҗрибәсен үрнәк итеп китерде ул.

– Комсомол районында бер мәктәп директоры үзе йөреп, укуны биш көнгә калдырган. Бер көне исә мәдрәсәдә белем алуга бирелә. Бөтенесе дә мәдрәсәгә йөри, гарәп телен өйрәнә. Менә алар ничек итеп телне, гореф-гадәтне саклый! – дип сөйләде Рима Сафиуллова.

Журналист Вәсилә Рәхимова да тәрбия мәсьәләсенә игътибар юнәлтте.

– Хәзерге буын балаларының әби-бабай сүзенә бик үк колак саласы килми. Алар өчен дәү әти дә, дәү әни дә – телефон. Минем үземнең дә биш онык. Иң олысына – 14 яшь, буйга җиткән кыз. Алар белән дә ипләп сөйләшергә тырышам, – ди ул. – Оныгыма «татар баласы син, мөселман кызы» дип әйтәм, аңлатам. Синең кимчелегеңне күргән кеше, иң элек: «Сине кем тәрбияләде?» – дип сорар, ояты иң башта безгә төшәр, дим. Дөрес өйрәтәмме-юкмы – белмим. Безне шулай үстерделәр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 6697 данә**
**Гомуми тираж – 15337 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 364

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**
**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+